ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
З.Кызыл ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 326

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«30» октябрь 2017 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясын, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карарлары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Милекчелек формасына бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту кагыйдәләренең үтәлүенә, торак йортларның, күпфатирлы йортларның энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аларның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә туры килүенә, шулай ук торак урыннарның, коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты, күләме һәм тәртибе законнардагы таләпләргә җавап бирүенә дәүләт контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламент раслау турында» 2010 елның 07 июлендәге 39 номерлы боерыгының көчен югалтуын танырга.

3. Хокук идарәсенә дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге Боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен оештырырга.

4. Әлеге Боерык үтәлешен тикшереп тору өчен үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А.Крайнов.

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
2017 елның «30» октябрендәге
326 номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан
Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген
гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең
административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен (алга таба – дәүләт функциясе) үтәгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең (алга таба – Инспекция) административ процедураларының һәм административ гамәлләренең вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮЧЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ БАШКАРМА ОРГАНЫ ИСЕМЕ

1.2. Дәүләт функциясен үтәү Инспекция һәм аның территориаль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт функциясе турыдан-туры Инспекциянең функциональ бүлекләре (алга таба – Бүлек), Инспекциянең Хокук идарәсенең административ тәҗрибә бүлеге (алга таба – административ тәҗрибә бүлеге) тарафыннан үтәлә.

Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүчеләр булып Инспекциянең Татарстан Республикасы дәүләт торак инспекторлары булып торучы вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар, дәүләт торак инспекторлары) тора.

Дәүләт функциясен үтәгәндә вазыйфаи затлар Татарстан Республикасының прокуратура органнары (алга таба – прокуратура органнары), экспертлар, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, үзкөйләнешле оешмалар, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешләрдә тора.

«Бердәм тикшерүләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – бердәм тикшерүләр реестры) мәгълүматлар кертү Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

# ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ҮТӘЛҮНЕ ҖАЙГА САЛА ТОРГАН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе;
- «Кулланучыларның хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 2300-1 номерлы Федераль закон) (Российская газета, 1996, 16 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 1, 14 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Российская газета, 2001, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба – РФ ГК), (Российская газета, 1994, 8 декабрь. кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 184-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1999, № 42, 5005 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 184-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2002, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2003, 8 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2006, 11 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2008, 30 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 261-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2009, 27 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);
- «Биналарның һәм корылмаларның ышанычлылыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 384-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2009, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 25 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 5, 546 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле дип тану турында нигезләмә раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 47 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 6, 702 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын һәм күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслардан файдалану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 306 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 22, 2338 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта уртак мөлкәт белән эш итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешсез сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән озынлыгын артып китүче өзеклекләр белән хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 34, 3680 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларын тәэмин итү өчен газ китертү тәртибе турында» 2008 елның 21 июлендәге 549 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 549 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 30, 3635 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартын раслау турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 731 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 731 номерлы карары белән расланган Стандарт), (Российская газета, 2010, 1 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 22, 3168 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергия саклау турында һәм энергетика

нәтиҗәлелеген арттыру турында законнардагы таләпләрнең үтәлүенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 25 апрелендәге 318 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 318 номерлы карары) (Российская газета, 2011, 29 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерация Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге һәм аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 290 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 12 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201304120004, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эче һәм фатир эче газ җайланмасыннан файдаланганда һәм аны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү чаралары турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 410 номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 24 май, басылып чыгу номеры: 0001201305240001, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 15 маендагы 416 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 416 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 22 май, басылып чыгу номеры: 0001201305220001, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2013 елның 11 июнендәге 493 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 493 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 17 июнь, басылып чыгу номеры: 0001201306170023, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар

тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст.);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру турында» 2009 елның 27 мартындагы 93 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Генпрокуратурасының 93 номерлы боерыгы) («Законность» басмасы, № 5, 2009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары (алга таба – ПиН) (Российская газета, 2003, 23 октябрь);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмаларның мәгълүмат ачу стандартын үтәвенә тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2012 елның 9 апрелендәге 162 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 162 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2012, 25 май);

- Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен, шул исәптән муниципаль торак контроле органнарының Россия Федерациясе субъектларының төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибен һәм дәүләт торак күзәтчелеге һәм муниципаль торак контроле буенча функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 23

августындагы 360 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 360 номерлы боерыгы) («Нормирование в строительстве и ЖКХ» басмасы, № 5, 2013);

- Татарстан Республикасы Конституциясе;

- «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 16-ТРЗ номерлы Закон) (Республика Татарстан, 2014, 2 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 72-ТРЗ номерлы Закон), (Республика Татарстан, 2011, 21 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) (Республика Татарстан, 2013, 28 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары (алга таба – ТР МК 1068 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2012, № 10, 0383 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга минималь кертем күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карары (алга таба – ТР МК 450 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2014, № 29, 0846 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2018 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләргә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 283 номерлы карары (алга таба – ТР МК 283 номерлы карары),(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 2014, № 37, 1159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТОРАК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ПРЕДМЕТЫ

1.4. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан, милекчелек рәвешенә бәйсез рәвештә, торак фондыннан файдалануга һәм саклауга карата торак законнары, энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда билгеләнгән таләпләрнең, шул исәптән торак урыннарына, алардан файдалану һәм аларны карап тотуга, күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләренең уртак

мөлкәтеннән файдалануга һәм аны саклауга, капиталь ремонт фондлары төзүгә, күпфатирлы йортлар белән идарәү итүне гамәлгә ашыручы, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яисә) эшләр башкаручы, күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүче юридик затларны, шәхси эшкуарларны, төбәк операторларын булдыруга һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләрнең үтәлүе, коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләренең, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм методларына, шулай ук коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану буенча билгеләнгән норматив күләменең нигезле булу-булмавына карата таләпләрнең, энергетика нәтиҗәлелеге һәм күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда биналарның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җиһазлары белән тәэмин ителү таләпләренең, социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннар бирүгә карата, махсуслаштырылган оешма белән йорт эче һәм (яисә) фатир эче газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау турында шартнамә булуга карата таләпләрнең (алга таба – зарури таләпләр) бозылуы төбәк дәүләт торак күзәтчелегенең предметы булып тора.

Төбәк дәүләт торак күзәтчелеге шушы пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затларга тикшерүләр оештыру һәм уздыру, зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чаралар, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган чараларны уздыру, ачыкланган бозуларны чикләү һәм (яисә) юкка чыгару буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү, зарури таләпләрнең үтәлүен системалы рәвештә күзәтү, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда зарури таләпләрнең үтәлү торышын анализлау һәм фаразлау (алга таба – системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау) юлы белән гамәлгә ашырыла.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТОРАК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ОБЪЕКТЛАРЫ

1.5. Дәүләт функциясе дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, юридик затларга, шәхси эшкуарларга һәм гражданнарга карата гамәлгә ашырыла.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТОРАК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ӨЧЕН ХОКУКЛАР, БУРЫЧЛАР ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР

1.6. Дәүләт функциясен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан һәм гражданнардан зарури таләпләрнең үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны нигезләнгән язмача гарызнамәләр нигезендә соратырга һәм алырга;

2) хезмәт таныклыгын һәм Инспекция җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерү билгеләү турында әмернамәсе күчермәсен күрсәтеп, территориягә һәм анда урнашкан күпфатирлы йортларга, социаль файдаланудагы наем йортларына, күпфатирлы йортларда уртак файдалану урыннарына каршылыкларсыз үтеп керергә; күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре ризалыгы белән торак урыннарына керергә һәм аларны тикшерергә; контрольлек чаралары буенча тикшеренүләр, сынаулар, тикшерүләр, экспертизалар һәм башка чаралар уздырырга, социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарын наймга бирүчеләр тарафыннан мондый йортларда торак урыннарын наймга бирүчеләргә һәм наймга алучыларга карата, социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләрен төзүгә һәм үтәүгә карата зарури таләпләрнең үтәлүен, Россия Федерациясе Торак кодексының 91.18 статьясының 2 өлешендә каралган затлар тарафыннан социаль файдаланудагы наем йортларының муниципаль реестрында исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне раслый торган документларны тапшыруга карата таләпләрнең үтәлүен тикшерергә; торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставының мондый ширкәтнең яисә мондый кооперативның уставына кертелгән үзгәрешләрнең Россия Федерациясе таләпләренә җавап бирүен тикшерергә; күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гаризалары буенча күпфатирлы йортта биналарның милекчеләрнең гомуми җыелышында торак милекчеләре ширкәте төзү турында карар кабул итүнең хокуклы булуын, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы идарәсен сайлауның хокуклы булуын, торак милекчеләре ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышында яисә торак милекчеләре ширкәте идарәсе тарафыннан мондый ширкәтнең рәисен сайлауның хокуклы булуын, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан мондый кооператив идарәсе рәисен сайлауның хокуклы булуын, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышында, Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясы нигезендә аның белән шартнамә төзү максатында, идарәче оешма сайлау турында карар кабул ителүнең хокуклы булуын, әлеге шартнамәнең һәм аны төзүнең шартларын раслауның хокуклы булуын, идарәче оешма белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару шартнамәсе төзүнең хокуклы булуын, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару шартнамәләрен төзүнең хокуклы булуын, мондый шартнамәләрнең шартларын раслауның хокуклы булуын тикшерергә;

3) зарури таләпләр бозылуны туктату турында, ачыкланган бозуларны бетерү турында, зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар уздыру турында, шул исәптән мондый күрсәтмәне җибәргән көннән соңгы алты айлык чорда торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставының уставка кертелгән үзгәрешләрнең зарури таләпләргә туры килмәгән өлешләрен юкка чыгару турында күрсәтмәләр бирергә;

4) зарури таләпләрне бозуга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, күрсәтелгән административ хокук бозулар турында эшләр карарга һәм мондый бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә;

5) җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга зарури таләпләр бозылуга бәйле материаллар җибәрергә;

6) түбәндәге гаризалар белән судка мөрәҗәгать итәргә:

күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышында яисә торак милекчеләре ширкәтенең, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен бозып кабул ителгән карарны гамәлгә ярашсыз дип тану турында;

торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын, билгеләнгән чорда мондый ширкәтнең яисә мондый кооперативның уставындагы мондый ширкәтнең яисә мондый кооперативның уставына кертелгән үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләренә туры килми торган өлешләрен юкка чыгару турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта яисә мондый ширкәтне яисә мондый кооперативны төзү тәртибен бозулар ачыкланган очракта, әгәр бу бозулар бетереп булмый торган холыкка ия булса, ликвидацияләү турында;

күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару шартнамәсен яки күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) ремонтлау буенча эшләр башкару шартнамәсен билгеләнгән чорда Россия Федерациясе Торак кодексындагы идарәче оешма сайлау турында, күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе шартларын раслау турында һәм аны төзү турында, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару шартнамәсен яисә күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) ремонтлау буенча эшләр башкару шартнамәсен төзү турында, күрсәтелгән шартнамәләрнең шартларын раслау турында таләпләр бозылуны юкка чыгару турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта гамәлгә ярашсыз дип тану турында;

торак урыннары милекчеләренең, торак урыннарын наймга алучыларның һәм башкача файдаланучыларның, аларның мөрәҗәгате буенча, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап яисә зарури таләпләр бозылу очрагы ачыкланганда билгеле булмаган затлар даирәсенең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап;

социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсен, билгеләнгән чорда әлеге шартнамәдә Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән зарури таләпләргә туры килмәгән өлешләрен юкка чыгару турында күрсәтмә үтәлмәгән очракта, гамәлгә ярашсыз дип тану турында;

7) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләре нигезендә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр бирергә.

1.7. Дәүләт функциясен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләрне бурычлы:

1) зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм тыю буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырылучы юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) Инспекция җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерү билгеләү турындагы әмернамәсенә нигезләнеп, тикшерү уздырырга;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныкларын, Инспекциясе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әмернамәсе күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү уздыруның килештерелүе турында документ күчермәсен күрсәткәндә генә уздырырга;

5) юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне уздырганда катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерү уздырганда катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча кабул ителә торган чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның бозуларның авырлыгына, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметлары һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документлар өчен, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү өчен потенциаль куркынычлылыгына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез чикләнүгә юл куймаска;

10) юридик зат, шәхси эшкуар шикаять белдергәндә үзенең гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерү уздыруның 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вакытларын сакларга;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм бүтән белешмәләрне таләп итмәскә;

13) урынга чыгып тикшерү уздыра башлар алдыннан юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуарның, аның

вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны тикшерү уздыруга нигез булган әлеге Регламент кушымталары белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәргә.

1.8. Дәүләт функциясен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләрне хокуклы түгел:

1) зарури таләпләр һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшерергә, әгәр дә мондый таләпләр шушы вазыйфаи затларга эш йөкләгән Инспекция вәкаләтләренә карамаса;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр үтәлешен, шулай ук үтәлеше Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган зарури таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) тикшерүне уздырганда юридик зат җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә аның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмый торган очракта, планлы яисә урынга чыгып планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга, мондый тикшерү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигез буенча уздырылган очрактан тыш;

5) әгәр тикшерү объектлары булып тормаса яисә тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның нөсхәләрен алырга;

6) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мөхит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган бүтән норматив техник документларда һәм тикшеренүләрнең, сынауларның, үлчәмнәр алуларның кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

7) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерү уздыру өчен билгеләнгән чорларны арттырырга;

9) юридик затларга, шәхси эшмкуарга алар хисабына контрольлек буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирүне гамәлгә ашырырга;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан, рөхсәт документларын да кертеп, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство карамагында торучы оешмалардан РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт

контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан соратыла торган һәм шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан алына торган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар исемлегенә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны тапшыруны таләп итәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. Инспекция, тикшерү уздыру турында әмернамә кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Үзләренә карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү уздырганда турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Инспекциядән, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына карый торган, тапшырылуы Россия Федерациясе законнарында каралган мәгълүматны алырга;

3) Инспекция тарафыннан документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Инспекциягә үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук Инспекциянең вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

6) тикшерү уздырганда Инспекциянең вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршында шәхси эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршында шәхси эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә;

1.10. Үзләренә карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затларның бурычлары:

1) юридик затдарның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яисә вәкаләтле вәкилләре катнашуны тәэмин итәргә; шәхси эшкуарлар үзләре катнашырга яисә зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү

буенча чараларны оештыру һәм уздыру өчен җаваплы булган вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш.

2) Инспекциянең вазыйфаи затларына тикшерүне уздырганда төбәк дәүләт торак күзәтчелеге объектларына керүне тәэмин итәргә;

3) билгеләнгән тәртиптә тикшерү уздырылганда Инспекциянең вазыйфаи затлары таләбе буенча тикшерү уздырганда кирәкле белешмәләрне һәм документларны тапшырырга.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ НӘТИҖӘЛӘРЕН СУРӘТЛӘҮ

1.11. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары турында белешмәләрне үз эченә алган, тикшерү актының Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган типик рәвешенә туры китереп, ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты;

2) тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) урынга чыгып уздырылган тикшерү турында язу (тикшерүләрне исәпкә алу журналының рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланды);

3) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланганда, шул исәптән административ хокук бозу составы билгеләре булганда:

4) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәләр, мондый бозуларны бетерү чорларын билгеләп, ул тикшерү актына кушымта булып тора;

5) административ хокук бозу турында беркетмә (РФ КоАП каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда).

Әгәр тикшерү барышында Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан законнардагы таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланса, аларны ачыклау, чикләү һәм тыю мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә кагылмаса, мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) үз эченә алган хатлар Россия Федерациясенең тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына яисә Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ҖИТКЕРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Инспекциянең урнашкан урыны һәм, дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне Инспекциягә җибәрү өчен, аның почта адресы: Зур Кызыл ур., 15/9 й., Казан ш., Татарстан Республикасы, 420111.

2.2. Инспекциянең эш графигы:

дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

җомга – 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр;

төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Бәйрәм алды көннәрендә эш көне 1 сәгатькә кыскартыла.

Инспекциянең территориаль органнары турында мәгълүмат шушы Регламентка 1 нче кушымтада урнаштырылган.

2.3. Инспекциянең белешмә телефоннары:

- Казан ш. халкы өчен телефон – (843) 555-69-01 (Казан шәһәре торак инспекциясе);
- Яр Чаллы, Тукай, Минзәлә һәм Актаныш районнарында яшәүчеләр өчен – (8552) 71-38-42 (Яр Чаллы зонасы торак инспекциясе);
- Әлмәт, Мөслим, Сарман һәм Чирмешән районнарында яшәүчеләр өчен – (8553) 45-77-75 (Әлмәт зонасы торак инспекциясе);
- Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Лениногорск һәм Ютазы районнарында яшәүчеләр өчен – (85594) 6-05-45 (Бөгелмә зонасы торак инспекциясе);
- Түбән Кама, Зәй һәм Яңа Чишмә районында яшәүчеләр өчен – (8555) 42-37-33 (Түбән Кама торак зонасы инспекциясе);
- Алабуга, Әгерҗе, Мамадыш һәм Менделеевск районнарында яшәүчеләр өчен – (85557) 3-10-77 (Алабуга зонасы торак инспекциясе);
- Чистай, Алексеевск, Әлки, Аксубай, Нурлат һәм Спас районнарында яшәүчеләр өчен – (84342) 5-05-13 (Чистай зонасы торак инспекциясе);
- республиканың калган 18 районында яшәүчеләр өчен (Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Тәтеш һәм Теләче районнары) – (843) 236-96-53 (Үзәк инспекторлык бүлеге).

Инспекция һәм Инспекциянең территориаль органнары турында мәгълүмат дәүләт функциясен башкару урыннарындагы стендларда, массакүләм мәгълүмат чараларында, Инспекциянең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) www.gji.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырыла.

2.4. Дәүләт функциясен гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

«Интернет» челтәрендә Инспекциянең www.gji.tatar.ru рәсми сайтында;

телефон элемтәсе чараларыннан файдаланып, язмача рәвештә, шулай ук tatgi@tatar.ru электрон почтасы аша;

Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә.

Инспекциянең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

Инспекция җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

Инспекциянең урнашкан урыны һәм почта адресы;

Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының эш графигы;

күзәтчелек объектларына планлы тикшерүләр уздыруның еллык планы (алга таба – тикшерүләр планы);

Инспекция тарафыннан уздырылган тикшерүләрнең нәтиҗәләре хакында мәгълүмат;

кушымталары белән бергә әлеге Регламент тексты;

дәүләт функциясе үтәлешен регламентлаучы норматив хокукый актлар;

Инспекциянең дәүләт функциясен үтәүче вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе;

бозуларны кисәтүнең ел саен раслана торган программасы;

төбәк дәүләт торак күзәтчелегенең тикшерү предметы аларның үтәлешен бәяләүдән гыйбарәт булучы зарури таләпләрне үз эченә ала торган норматив хокукый актларның яки аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

зарури таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук зарури таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Зарури таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге зарури таләпләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук зарури таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елга бер мәртәбәдән ешрак түгел), юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуга юл куелмау максатларында күрелергә тиешле чаралар буенча киңәшләр белән, мондый бозуларның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп.

2.5. Дәүләт функциясен гамәлгә ашыру процедурасы турында консультацияләр түбәндәгечә тапшырыла:

а) шушы Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән адрес буенча җибәрелгән язмача мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән әлеге Регламентның 2.4 пунктында күрсәтелгән электрон почта адресы буенча;

б) телефоннар буенча;

в) Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә.

2.6. Гражданнарны шәхсән кабул итү Инспекция җитәкчесе һәм аның урынбасарлары тарафыннан гражданнарны кабул итү графигы нигезендә уздырыла.

| | | |
|---|---|---|
| Инспекция җитәкчесе | сишәмбе | 14.00 - 18.00 |
| Җитәкче урынбасарлары | сишәмбе | 14.00 - 18.00 |

2.7. Дәүләт функциясен турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар мәгълүматларны телефон ярдәмендә түбәндәге мәсьәләләр буенча бирә:

дәүләт функциясе үтәлүне җайга сала торган норматив хокукый актлар турында;

дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында;

дәүләт функциясен үтәү чорлары турында;

Инспекциянең урнашкан урыны һәм эш графигы турында;

Инспекция сайты адресы турында;

дәүләт функциясен үтәү барышы турында.

2.8. Бүтән мәсьәләләр Инспекция тарафыннан бары тик тиешле язмача мөрәҗәгать нигезендә генә карала.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРДАН ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТОРАК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ УЗДЫРГАН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАГАНЛЫГЫ

2.9. Үзләренә карата дәүләт функциясе гамәлгә ашырыла торган затлардан төбәк дәүләт торак күзәтчелеге буенча чараларны уздырган өчен, шул исәптән экспертларның һәм эксперт оешмаларның хезмәтләре өчен, аларны тикшерү уздыруга җәлеп иткән очракта, түләү алынмый.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ

2.10. Планлы яисә планнан тыш (документар, урынга чыгып) тикшерү уздыру вакыты, төбәк операторларына карата тикшерүләрдән тыш, егерме эш көненнән артык була алмый.

Төбәк операторлары эшчәнлеген тикшерүләр теләсә нинди ешлык белән һәм планлы тикшерүләр уздыруның еллык планын формалаштырмыйча уздырыла. Тикшерүләр уздыру чоры чикләнми.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр уздыруның гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, Инспекциянең урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга чыгып планлы тикшерү уздыру вакыты Инспекция җитәкчесе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата тикшерү (документар, урынга чыгып) уздыру вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерү уздыруның гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артык була алмый.

Кече эшкуарлык субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерү уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурлыгы килеп чыккан очракта, Инспекция җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе ун эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында,

бүлмәләрендә, бүтән объектларында Инспекциянең күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

2.11. Планлы тикшерүләр, төбәк операторларыннан кала, елына бер мәртәбәдән артык булмаган ешлыкта уздырыла.

## ТИКШЕРҮЛӘРНЕ УЗДЫРУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.12. Планлы тикшерүләр Инспекция тарафыннан эшләнә һәм раслана торган тикшерүләрнең еллык планнары нигезендә уздырыла.

2.13. Планлы тикшерүне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү өчен түбәндәге көннән бер ел узып китү нигез булып тора:

1) Инспекциягә күрсәтелгән эшчәнлекне башлау турында тапшырылган хәбәрнамә нигезендә юридик затның, шәхси эшкуарның күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлеге һәм күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару буенча эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган көннән соң;

2) социаль файдаланудагы беренче наем йорты социаль файдаланудагы наем йортларының муниципаль реестрында исәпкә алынганнан соң, – андагы торак урыннарын наемга тапшыручы булып эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат торса;

3) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерү тәмамланган көннән соң;

4) коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары билгеләнгән соң яисә үзгәртелгән көннән соң.

2.14. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) зарури таләпләрнең һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан бозылуының ачыкланган очракларын бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты узу;

2) Инспекция вазыйфаи затының дәлилле йогынты акты, – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан Инспекциягә килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, – түбәндәге фактлар турында:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салыну, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зарар килү, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей

фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зарар килү, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган кулланучыларның, гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең үзенең бозылган хокукларын яклау (торгызу) буенча юридик затка, шәхси эшкуарга мөрәҗәгать итүе һәм мондый мөрәҗәгатьнең карап тикшерелмәгән булуы яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булуы шарты белән);

3) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.1 статьясының 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен гамәлгә ашырганда, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә чаралар уздырганда юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегендә Инспекция тарафыннан расланган куркыныч индекаторы буенча аларга туры килү яисә алардан тайпылу федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре турында нигезләмәдә каралганча планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып торган параметрлар ачыклану;

4) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү уздыру турындагы таләбе нигезендә чыгарылган Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әмернамәсе;

5) Инспекциягә, асылда система ярдәмендә, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүматлар килү, мәгълүмат системасында түбәндәгеләргә карата таләпләрнең бозылу фактлары турында ачыклау:

а) торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы төзү тәртибенә;

б) торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставына һәм мондый ширкәтнең яисә мондый кооперативның уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә;

в) күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең, идарәче оешманың күпфатирлы йорт белән идарә шартнамәсен төзү максатларында, күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, оешу-хокук рәвешенә бәйсез рәвештә, юридик затны яисә шәхси эшкуарны (алга таба – идарәче оешма) сайлау турында карар кабул итү тәртибенә;

г) идарәче оешма белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару шартнамәсе төзү турында карарларга, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) ремонтлау буенча эшләр башкару шартнамәләрен төзү турында карарга, әлеге шартнамәләрнең шартларын раслау һәм аларны төзү тәртибенә, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту һәм шушы йортта уртак мөлкәткә агымдагы һәм капиталь

ремонтны гамәлгә ашыру тәртибенә, идарәче оешманың Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган йөкләмәләрен бозу фактлары турында;

д) коммуналь хезмәтләргә гражданнар тарафыннан кертелүче түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендә бозу фактлары турында, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалануның билгеләнгән норматив күләменең нигезсез булуы, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына карата таләпләрне һәм коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү методлары бозылу фактлары турында, социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарын наймга тапшыручылар тарафыннан мондый йортларда торак урыннарын наймга бирүчеләргә һәм наймга алучыларга карата, социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләрен һәм торак урыннарның найм шартнамәләрен төзүгә һәм үтәүгә карата билгеләнгән зарури таләпләрнең бозылу фактлары турында.

2.15. Инспекциягә мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, Инспекциянең вазыйфаи заты, мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан бары тик бердәм идентефикацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булуы шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә ала.

2.16. Шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшергәндә элегрәк килгән, охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.17. Зарури таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, зарури таләпләрне бозу турында яисә шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин.

Беренчел тикшерүне үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүматлар җиткергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшкуарның Инспекция карамагында булган документлары карап тикшерелә, зарурлык булганда, юридик зат, шәхси эшкуар белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматлар тапшыру һәм Инспекция таләпләрен үтәү буенча

бурычлар йөкләмичә генә контрольлек чаралары үткәрелә. Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

2.18. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча зарури таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, зарури таләпләрне бозу турында яисә шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә мәгълүматлар алынганда, Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты, шушы Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле йогынты акты әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.19. Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) карары буенча, әгәр дә тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр китерелүе ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

Инспекция, әгәр дә гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданнан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан, аталган затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә Инспекция тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## ИНСПЕКЦИЯНЕҢ ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ ТОРАК КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ

2.20. Инспекциянең төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган вазыйфаи затларының исемлеге шушы Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелде.

Тикшерүләр Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) әмернамәсе белән тикшерү үткәрүгә вәакләт бирелгән Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан турыдан-туры уздырыла.

## 294-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫ БУЛУЫ

2.21. Тикшерүләрне уздырганда юридик затлар юридик затларның җитәкчеләренең, бүтән вазыйфаи затларының яисә вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш; шәхси эшкуарлар үзләре катнашырга яисә зарури таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыруга һәм уздыруга җаваплы булган вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә тиеш.

294-ФЗ номерлы Федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) билгеләнгән чорларда Инспекциянең зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән

вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ТИКШЕРҮ УЗДЫРГАНДА ИНСПЕКЦИЯНЕҢ, АНДАГЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫ БУЛУЫ

2.22. Инспекция, андагы вазыйфаи затлар тикшерү уздырганда, тиешенчә, функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, хокукка каршы килә торган гамәлләр кылганда (гамәл кылмаганда), Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Инспекция вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә Инспекция язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итәргә бурычлы.

## 3. КҮЗӘТЧЕЛЕК ОБЪЕКТЛАРЫНА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Күзәтчелек объектларына карата белдерелә торган, үтәлеше контрольдә тотыла торган зарури таләпләр, мондый зарури таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар исемлеге 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица – Күзәтчелек объектларына карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Контрольлек объектлары (эшчәнлек төрләре, контрольлек төрләре) | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт | Зарури таләпнең үтәлүен раслый торган документлар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Милекчелек формасына бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалану һәм аны саклау | Торак урын гражданнарга яшәү өчен билгеләнгән.<br>Торак урыннарда сәнәгый җитештерүләрне урнаштыру, шулай ук торак урыннарда миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру рөхсәт ителми, «Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 | РФ ТК 17 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 25 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш. | | |
| | Торак урыннан файдалану шушы торак урында яшәүче гражданнарның, күршеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, янгын куркынычсызлыгы, санитария-гигиена, экология таләпләренең һәм законнардагы бүтән таләпләрнең үтәлүен исәпкә алып, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган торак урыннардан файдалану кагыйдәләренә туры китереп гамәлгә ашырыла. | РФ ТК 17 ст. | - |
| | Торак урын милекчесе әлеге торак урынны тиешле тәртиптә, аның белән хуҗалыксыз эш итүгә юл куймыйча карап тотарга, күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен, шулай ук күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту кагыйдәләрен сакларга тиеш. | РФ ТК 30 ст. | - |
| Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту | Уртак мөлкәт Россия Федерациясе законнары таләпләренә (шул исәптән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, техник җайга салу, кулланучыларның хокукларын яклау турында) туры китереп, түбәндәгеләрне тәэмин итәрлек торышта карап тотылырга тиеш:<br>а) күпфатирлы йортның ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламалары үтәлүне;<br>б) гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлыкны, физик яисә юридик затларның мөлкәте, дәүләти, муниципаль һәм бүтән мөлкәтнең саклануын;<br>в) торак һәм (яисә) тору өчен билгеләнмәгән биналардан, уртак файдаланудагы биналардан, шулай ук күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлегеннән, шул исәптән инвалидлар һәм халыкның аз мобильләшкән башка төркемнәре өчен файдалану мөмкинлеген;<br>г) биналарның милекчеләренең, шулай | РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ук бүтән затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлүен;<br>д) инженерия коммуникацияләренең, исәпкә алу һәм уртак мөлкәт составына керә торган башка җайланмаларның күпфатирлы йортта яшәүче гражданнарга Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре (алга таба – Коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре) нигезендә коммуналь хезмәтләр бирү (коммуналь ресурслар җиткерү) өчен даими әзер торуын;<br>е) күпфатирлы йортны төзү яисә үзгәртеп кору өчен проект документациясе нигезендә күпфатирлы йортның архитектур кыяфәтен карап тотуны;<br>ж) энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында Россия Федерациясе законнары таләпләре үтәлүне. | | |
| Торак урынны торак булмаган һәм торак булмаганны торак урынга күчерү тәртибе | Торак урыннан башка максатларда файдалану бары тик аны торак булмаган итеп күчергәннән соң гына рөхсәт ителә | РФ ТК 3 бүлеге | Җирле үзидарә органы карары |
| Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган нигезләмә нигезендә, торак урыннарны торак өчен билгеләнгән дип, торак урыннарны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле дип тану тәртибе | Бинаны аны яшәү өчен билгеләнгән торак урын, торак урынны гражданнарга яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану максатларында, шулай ук күпфатирлы йортны аны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле дип тану максатларында бәяләү һәм тикшерү шушы максатларда төзелә торган ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм биналарның һәм йортның шушы Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәве предметы буенча уздырыла.<br><br>Комиссия составына төбәк дәүләт торак күзәтчелеген уздыруга вәкаләтле органнар вәкилләре кертелә | РФ ТК 15 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмә | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Торак фондын исәпкә алу | 1. Күпфатирлы йорт (алга таба – КФЙ) турында гомуми белешмәләр:<br>- КФЙ белән идарә итү ысулы турында белешмәләр;<br>- КФЙ капиталь ремонт фондын төзү ысулы турында белешмәләр;<br>- КФЙ гомуми сыйфатлама<br>(адресы; төзелгән/йортны эксплуатациягә керткән елы; сериясе; төзелү тибы; катлар, подъездлар, лифтлар, биналар саны; йортның гомуми мәйданы; җир кишәрлегенең кадастр номеры; җир кишәрлегенең мәйданы; төзекләндерү элементлары).<br>2. Күпфатирлы йортның төп конструктив элементлары, КФЙ уртак мөлкәт составына керүче җайланмалар һәм инженерия-тәэминат системалары турында белешмәләр. | Россия Төзелеш министрлыгының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 22 декабрендәге 882/пр номерлы боерыгы | - |
| Торак урыннарны үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру тәртибе | Торак урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру җирле үзидарә органы кабул иткән карар нигезендә аның белән килешү буенча, законнардагы таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла. | РФ ТК 4 бүлеге | - |
| Социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннары бирү | Наем йортлары белән идарә итү РФ ТК 161 статьясының 1-1.2, 15 һәм 16 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, мондый йортта торак урыннарын наймга бирүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла, әгәр мондый йортның яисә андагы биналарның милекчесе тарафыннан мондый йорт белән идарә итүнең РФ ТК 162 статьясы нигезендә милекче яисә ул вәкаләт биргән наймга бирүче белән төзелгән идарә итү шартнамәсе буенча РФ ТК 161 статьясының 2.3, 9 һәм 10 өлешләре нигезендә идарәче оешма тарафыннан гамәлгә ашырылуы турында карар кабул ителмәгән булса. | РФ ТК III бүлеге | - |
| Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәте составын | КФЙ уртак мөлкәте составына түбәндәгеләр керә:<br>а) КФЙ фатир өлешләре булып тормаган һәм шушы КФЙ бердән артык торак һәм (яисә) торак булмаган бинага хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән урыннар (алга | РФ ТК 36 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары белән | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| билгеләү, аны карап тоту һәм файдалану | таба – уртак файдалану урыннары), шул исәптән фатирлар арасындагы баскыч мәйданнары, баскычлар, лифтлар, лифт һәм бүтән шахталар, коридорлар, коляска урыннары, чормалар, техник катлар (биналарның милекчеләре акчасына терәп төзелгән гаражлар һәм автомобиль транспорты өчен мәйданнар, остаханәләр, техник чормалар) һәм инженерия коммуникацияләре булган техник подваллар, чүп кабул итү камералары, чүпүткәргечләр, КФЙ бердән артык торак һәм (яисә) торак булмаган бинага хезмәт күрсәтүче бүтән җайланма (котельныйларны, бойлер, элеватор төеннәрен һәм башка инженерия җайланмаларын да кертеп);<br>б) түбәләр;<br>в) КФЙ киртәләп алган терәк конструкцияләр (фундаментларны, терәк стеналарны, түшәмә плитәләрен, балкон һәм бүтән плитәләрне, терәк колонналарны һәм киртәләп алучы башка терәк конструкцияләрне дә кертеп);<br>г) КФЙ бердән артык торак һәм (яисә) торак булмаган урыннарга хезмәт күрсәтүче, киртәләп алучы, терәк булмаган конструкцияләр (уртак файдалану урыннарындагы тәрәзәләрне һәм ишекләрне, тотынгычларны, парапетларны һәм терәк булмаган башка киртәләүче конструкцияләрне дә кертеп);<br>д) механик, электрик, санитар-техник һәм бүтән җайланма, шул исәптән КФЙ биналарына инвалидларга каршылыксыз үтеп керүне тәэмин итү өчен билгеләнгән, КФЙ биналардан читтә яисә биналар эчендә урнашкан һәм бердән артык торак һәм (яисә) торак булмаган урынга (фатирларга) хезмәт күрсәтүче конструкцияләр һәм (яисә) бүтән җайланма (алга таба – инвалидлар һәм халыкның аз мобильләшкән бүтән төркемнәре өчен җайланма);<br>е) КФЙ урнашкан һәм чикләре дәүләт кадастр исәбенә алу белешмәләре нигезендә билгеләнгән җир кишәрлеге, яшелләндерү һәм төзекләндерү элементлары белән бергә; | расланган кагыйдәләр | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | е(1)) коммуналь ресурсларны һәм хезмәтләрне куллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмати-үлчәү системалары, шул исәптән үлчәү комплекслары (исәпкә алу җиһазларының, күрсәткечләрне җыю һәм белешмәләрне тапшыру җайланмалары, исәпкә алу белешмәләрен җыю, саклау һәм тапшыру өчен программа продуктлары) җыелмасы, – КФЙ биналарның милекчеләре хисабына урнаштырылган очракларда, шул исәптән 261-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә исәпкә алу җайланмаларын урнаштыру йөкләмәсен үтәү кысаларында;<br>ж) КФЙ хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен билгеләнгән бүтән объектлар, бер КФЙ хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән трансформатор подстанцияләрен, җылылык пунктларын, күмәк автостоянкаларны, күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан гаражларны, балалар һәм спорт мәйданчыкларын да кертеп.<br>Уртак мөлкәт составына су агызу буенча йорт эче инженерия системасы керә, ул канализация суларын чыгару, фасон өлешләреннән (шул исәптән читкә чыгару, күчерү трубаларыннан, җиңсәләрдән, ревизияләр, әвернәләрдән, өч япьле көпшәләрдән), тоташтыручы торбалардан, томалагычлардан, суыртып алу трубаларыннан, агынты су бүрәнкәләреннән, тоташтыручы трубалардан беренче ялганыш трубаларна кадәр тармакланган иләгечләрдән, шулай ук шушы системада урнашкан башка җайланмалардан тора.<br>Уртак мөлкәт составына газ белән тәэмин итү буенча йорт эче инженерия системасы керә, ул газ чыганагыннан (сыегайтылган угелводородлы газ кулланганда) үткәрелгән газүткәргечләрдән яисә күрсәтелгән газүткәргечләрне газ бүлү челтәренә тоташтыру урыныннан томалагыч арматурага (кранга) кадәр тоташтыру урыныннан үткәрелгән, йорт эчендәге газ җайланмасына таба тармакланып, сыегайтылган углеводород газларының резервуарлы һәм (яки) | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төркемле баллон җайланмаларында урнашкан, бер күпфатирлы йортка газ бирү өчен билгеләнгән газ файдалану җайланмасыннан (фатир эчен газ җайланмасы составына керә торган көнкүрештә газдан файдалану җайланмасыннан тыш), газүткәргечләрдәге техник җайланмалардан, шул исәптән көйләүче һәм саклаучы арматуралардан, биналарның газлануын тикшереп тору системасыннан, газны исәпкә алуның күмәк (йорттагы гомуми) җиһазлардан, шулай ук җылыту һәм (яисә) кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтелгәндә файдаланыла торган газ күләмен терки торган газны исәпкә алу җиһазларыннан тора.<br>Уртак мөлкәт составына йорт эче җылыту системасы керә, ул ялгаучы трубалардан, җылытучы элементлардан, көйләүче һәм томалаучы арматурадан, җылылык энергиясен исәпкә алу буенча күмәк (йорттагы гомуми) җиһазлардан, шулай ук әлеге челтәрләрдә урнашкан башка җайланмадан тора.<br>Уртак мөлкәт составына электр белән тәэмин итүнең йорт эче системасы керә, ул кертүче шкафлардан, кертү-бүлү җайланмаларыннан, яклау, тикшереп тору һәм идарә итү аппаратурасыннан, электр энергиясен исәпкә алуның күмәк (йорттагы гомуми) җиһазлардан, катлардагы щитоклардан һәм шкафлардан, уртак файдаланудагы урыннарны яктырту җайланмаларыннан, төтен бетерү буенча электрика җайланмаларыннан, эчке янгынга каршы сууткәргечнең автомат янгын сигнализациясе системаларыннан, пассажирлар һәм янгын лифтларыннан, күпфатирлы йортның подъезд ишекләрен автомат рәвештә бикләүче җайланмалардан, РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 8 п. нигезендә тышкы чиктән электр энергиясен исәпкә алуның хосусый, гомуми (фатир) җиһазларына кадәр салынган челтәрләрдән (кабельләрдән), шулай ук шушы челтәрләрдә урнашкан башка электр | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җайланмаларыннан тора. | | |
| Күпфатирлы йорт белән идарә итү | КФЙ белән идарә итү гражданнарга иминлекле һәм куркынычсыз яшәү шартларын, КФЙ уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны, күрсәтелгән мөлкәттән файдалану мәсьәләләрен хәл итүне, шулай ук мондый йортта яшәүче гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш. Россия Федерациясе Хөкүмәте КФЙ белән идарә итү эшчәнлегенең стандартларын һәм кагыйдәләрен билгели. | РФ ТК 161 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 416 номерлы карары белән расланган Тәртип | - |
| Күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан (шул исәптән идарәче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш кооперативлары, шулай ук КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) ремонтлау буенча эшләр башкару эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан, мондый йортта | КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен тиешенчә карап тоту Россия Федерациясе законнарындагы, шул исәптән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге, техник җайга салу, янгын куркынычсызлыгы, кулланучыларның хокукларын яклау турындагы таләпләр нигезендә гамәлгә ашырылырга һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:<br>КФЙ ышанычлы һәм куркынычсыз булуына карата таләпләр үтәлүне;<br>гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге, физик затларның мөлкәте, юридик затларның мөлкәте, дәүләти һәм муниципаль мөлкәт өчен куркынычсызлыкны;<br>КФЙ биналардан һәм биналарның милекчеләренең уртак мөлкәте составына керә торган бүтән мөлкәттән файдалану мөмкинлеген;<br>КФЙ биналарның милекчеләренең, шулай ук бүтән затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлүне;<br>инженерия коммуникацияләренең, исәпкә алу һәм КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәт составына керә торган башка җайланмаларның КФЙ яшәүче гражданнарга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән КФЙ һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктату һәм чикләү кагыйдәләре нигезендә коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен даими әзер торуын.<br>КФЙ уртак мөлкәтне тиешенчә карап | РФ ТК 161 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 290 номерлы карары белән расланган Исемлек | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| биналарның милекчеләре тарафыннан КФЙ белән турыдан-туры идарә иткәндә) Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр һәм эшләр башкару | тотуны тәэмин итү өчен минималь кирәкле хезмәтләр һәм эшләр исемлеге составы, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. | | |
| Торак урынны карап тотуга түләү хисаплау тәртибен саклау | КФЙ уртак мөлкәткә бу йортта бина милекчесенең уртак милекчелек хокукындагы өлеше күрсәтелгән бинаның гомуми мәйданы зурлыгына пропорциональ була.<br><br>КФЙ уртак мөлкәтне карап тотуга шушы йортта бина милекчесе түләргә тиешле мәҗбүри чыгымнар өлеше күрсәтелгән милекченең мондый йортта гомуми мөлкәткә уртак милекчелек хокукындагы өлеше белән билгеләнә.<br>Торак урынны карап тоту өчен түләүгә КФЙ белән идарә итү буенча хезмәтләргә, эшләргә, КФЙ уртак мөлкәтне карап тотуга һәм агымдагы төзекләндерүгә, шулай ук, КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту максатларында, КФЙ уртак мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган салкын суга, кайнар суга, электр энергиясенә, агынты суларны җибәрүгә (алга таба шулай ук – КФЙ уртак мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар) түләү керә.<br>Торак милекчеләре ширкәте (алга таба – ТМШ) яисә торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы (алга таба – ТТК) төзелмәгән КФЙ торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме мондый йортта биналарның | РФ ТК 37, 39, 154, 156, 158 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | милекчеләренең гомуми җыелышында билгеләнә, ул РФ ТК 45-48 статьяларында билгеләнгән тәртиптә уздырыла, РФ ТК 156 статьясының 9.2 өлеше нигезендә билгеләнә торган чыгымнарның күләмнәреннән тыш. КФЙ торак урынны карап торткан өчен түләү күләме идарәче оешма тәкъдимнәрен исәпкә алып ачыклана һәм кимендә бер еллык чорга билгеләнә.<br>ТМШ яисә ТТК әгъзаларының КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлауга бәйле чыгымнарны түләүгә бәйле мәҗбүри түләүләренең һәм (яисә) кертемнәренең күләме ТМШ идарә органнары яисә ТТК идарә органнары тарафыннан ТМШ уставы яисә ТТК уставы нигезендә билгеләнә.<br>Торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), социаль найм шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча торак урыннарын наймга алучылар өчен торак урынны карап торткан өчен түләү күләме һәм КФЙ идарә итү ысулы турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап торткан өчен түләү күләме җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.<br>Әгәр КФЙ биналарның милекчеләре үзләренең гомуми җыелышында КФЙ торак урынны карап торткан өчен түләү күләмен раслау турында карар кабул итмәсә, КФЙ торак урынны карап торткан өчен җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән түләү күләме кулланыла. | | |
| Коммуналь хезмәтләргә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәсен саклау | Коммуналь хезмәтләргә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) раслаган чик (максималь) индекслардан югары дәрәҗә арттыру рөхсәт ителми. | РФ ТК 157.1 ст. | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган мәгълүмат ачу стандарты нигезендә мәгълүматны ачу | Идарәче оешма, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган мәгълүмат ачу стандарты нигезендә, үзенең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында, КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр турында, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе турында һәм шартлары турында, аларның бәясе турында, коммуналь хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле ресурсларга бәяләр (тарифлар) турында мәгълүматтан ирекле файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. КФЙ белән идарә итү буенча эшчәнлек турында мәгълүмат ачу һәм РФ ТК каралган документларны КФЙ белән идарә итүне (идарәче оешма белән шартнамә төземичә) гамәлгә ашыручы ТМШ яисә ТТК тарафыннан танышып чыгу өчен бирү үзенчәлекләре әлеге мәгълүмат ачу стандарты белән билгеләнә. | РФ ТК 161 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 731 номерлы карары белән расланган Стандарт | - |
| Торак милекчеләре ширкәтен яисә торак, торак-төзелеш яисә бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын төзү һәм аларның эшчәнлеге, алардагы әгъзаларның хокукларын һәм бурычларын саклау | Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышында ТМШ төзү турында карар кабул итүне хокуклы булуы, ТМШ, ТТК әгъзаларының гомуми җыелышында ТМШ, ТТК идарәсен сайлауның хокуклы булуы, ТМШ әгъзаларының гомуми җыелышында яисә ТТК идарәсе тарафыннан мондый ТМШ идарә рәисен сайлауның хокуклы булуы, ТТК идарәсе тарафыннан мондый ТТК рәисен сайлауның хокуклы булуы. | РФ ТК 20 ст. | - |
| Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр | Кулланучыга коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм аларның коммуналь хезмәтләр сыйфатына карата таләпләргә җавап бирүе. | РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| күрсәтү | | | |
| Күпфатирлы йортларның советларын төзү һәм аларның эшчәнлеге | Әгәр дә КФЙ ТМШ төзелмәсә яисә әлеге йорт ТТК тарафыннан идарә ителмәсә һәм бу йортта фатирлар саны дүрттән артык булса, әлеге йортта биналарның милекчеләре гомуми җыелышта әлеге йортта биналарның милекчеләре исәбеннән КФЙ советын сайларга тиеш.<br>РФ ТК 161.1 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән очракларда, бер календарь елы эчендә КФЙ советын сайлау турында карар биналарның милекчеләре тарафыннан кабул ителмәгәндә яисә тиешле карар тормышка ашырылмаган очракта, җирле үзидарә органы өч айлык чорда КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми җыелышын чакырта, аның көн тәртибенә әлеге йортта КФЙ советын, шул исәптән әлеге йорт советы рәисен сайлау турында яисә әлеге йортта ТМШ сайлау турында мәсьәләләр кертелә. | РФ ТК 161.1 ст. | - |
| Коммуналь хезмәтләргә түләү хисаплау тәртибен саклау | Коммуналь хезмәтләргә түләү күләме кулланыла торган коммуналь хезмәтләрнең аларны исәпкә алу җайланмаларының күрсәткечләре буенча билгеләнә торган күләменнән чыгып, ә мондый җайланмалар булмаганда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланучы коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларыннан (шул исәптән каты коммуналь калдыклар туплану нормативларыннан) чыгып хисаплана. Коммуналь хезмәтләр өчен түләү хисаплаганда КФЙ үзләренә караган биналарны кулланыла торган су, электр энергиясен исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка ия булмаган биналарның һәм мондый исәпкә алу җайланмалары белән җиһазланмаган биналарның милекчеләре өчен тиешле коммуналь хезмәт төреннән куллану нормативына карата Россия Федерациясе Хөкүмәте | РФ ТК 157 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тарафыннан билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә арттырылган коэффициентлар кулланыла. КФЙ һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләрне күрсәтү, туктату һәм чикләү кагыйдәләре, КФЙ һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләрнең аерым төрләрен күрсәтү үзенчәлекләре, тиешле шартнамәләрне төзү шартлары һәм тәртибе, шулай ук идарәче оешма яисә ТМК яки ТТК тарафыннан ресурс белән тәэмин итү оешмалары белән шартнамәләрне төзегәндә мәҗбүри кагыйдәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.<br>Коммуналь хезмәтләргә түләү күләмен хисаплау РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә башкарыла. | | |
| Күпфатирлы йортларның һәм торак йортларның энергетика нәтиҗәлелеген, аларның кулланыла торган энергетика ресурслар исәпкә алу җиһазлары белән тәэмин ителүен һәм мондый җиһазларның эксплуатацияләнүен тәэмин итү | Эксплуатациягә керткәндә энергетика нәтиҗәлелеге классы бирелгән күпфатирлы йортның КФЙ эксплуатацияләү барышында энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә җавап бирүе буенча дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе субъектының күрсәтелгән күзәтчелекне гамәлгә ашыру өчен вәкаләтле башкарма хакимият органы КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту кагыйдәләре үтәлешен тикшергәндә КФЙ энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә туры килүен билгеләү өчен кулланыла торган күрсәткечләрнең агымдагы саннарыннан һәм КФЙ турындагы бүтән мәгълүматлардан чыгып, КФЙ энергетика нәтиҗәлелеге классын билгели. КФЙ энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә туры килүен тикшерү акты күчермәсе, шушы актны төзегән вакытта КФЙ энергетика нәтиҗәлелеге классын күрсәтеп, шәһәр төзү эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып баруны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына җибәрелергә тиеш.<br>Торак фондыныда энергия нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен һәм аның | 261-ФЗ номерлы Федераль закон | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | энергетика ягыннан файдалылыгын арттыру максатларында КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тотуга таләпләр исемлегенә энергия саклау һәм КФЙ энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар уздыру турында таләпләр кертелә. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән принципларга нигезләнеп, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтенә карата энергия сакоау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча бер мәртәбә һәм (яисә) даими рәвештә уздырылырга тиешле чаралар исемлеген раслыйлар.<br>КФЙ карап тоту өчен җаваплы зат яисә, КФЙ белән турыдан-туры идарә иткәндә, КФЙ биналарның милекчеләре КФЙ биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтенә карата энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларның расланган исемлегенә кертелгән энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларны уздырырга бурычлы, күрсәтелгән чараларның элегрәк уздырылу яисә аларны уздыру нәтиҗәләре саклану очракларыннан тыш.<br>КФЙ биналарның милекчеләре күрсәтелгән чараларны уздырган өчен чыгымнар тотарга бурычлы. Күрсәтелгән чараларны уздырган өчен чыгымнарны киметү максатларында КФЙ биналарның милекчеләре КФЙ карап тоту өчен җаваплы заттан КФЙ кулланыла торган энергетика ресурслары күләмен киметүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкаруын һәм (яисә) шушы зат тарафыннан КФЙ кулланыла торган энергетика ресурслары күләмен киметүне тәэмин итүче энергосервис шартнамәсе (контракты) төзелүне таләп итәргә хокуклы.<br>КФЙ карап тоту өчен җаваплы зат даими рәвештә (елына бер мәртәбәдән ешрак түгел) энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча КФЙ уздырырга мөмкин булган чаралар | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында тәкъдимнәрне, аларны уздыру чыгымнарын, кулланыла торган энергетика ресурсларын киметүнең көтелгән күләмен һәм тәкъдим ителә торган чараларның чыгымнары каплану чорларын күрсәтеп, эшләргә һәм КФЙ биналарның милекчеләренең игътибарына җиткерергә бурычлы.<br>Җылыту чорында КФЙ карап тоту өчен җаваплы зат, КФЙ җылылык энергиясе чыгымнарын аны саклау максатларында җайга салуга юнәлдерелгән гамәлләрне, мондый җайга салуның техник мөмкинлеге булганда һәм җылылык һәм гидравлика режимнары, шулай ук коммуналь хезмәтләрнең сыйфатына карата таләпләр, санитар нормалар һәм кагыйдәләр үтәлгәндә, башкарырга бурычлы. КФЙ кулланыла торган җылылык энергиясе өчен исәп-хисаплар җылылык йөкләнеше зурлыгын исәпкә алып гамәлгә ашырылса, КФЙ карап тоту өчен җаваплы зат коммуналь хезмәтләр сыйфатына карата билгеләнгән таләпләр, санитар нормалар һәм кагыйдәләр үтәлгәндә җылылык йөкләнеше зурлыгын ачыкларга һәм, КФЙ биналарның милекчеләренең җылылык энергиясенә түләүдә чыгымнарын оптимальләштерү максатларында, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән гамәлләрне башкарырга бурычлы. КФЙ карап тоту өчен җаваплы зат шушы өлештәге таләпләр нигезендә уздырыла торган гамәлләр турында яисә технологик сәбәпләр буенча аларны уздыру мөмкинлегенең булмавы турында мәгълүматларны КФЙ биналарның милекчеләре игътибарына җиткерергә бурычлы.<br>2011 елның 1 гыйнварына кадәр 261-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә эксплуатациягә кертелгән һәм аларны эксплуатацияләгәндә энергетика ресурслары кулланыла торган биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм бүтән объектларның (шул исәптән вакытлыча объектларның) милекчләре мондый объектларның файдаланыла торган суны, табигый газны, җылылык энергиясен, | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | электр энергиясен исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин итүне, шулай ук урнаштырылган исәпкә алу җайланмаларын эксплуатациягә кертүне тәмамларга бурычлы.<br>2012 елның 1 июленә кадәр 261-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә эксплуатациягә кертелгән торак йортларның милекчеләре, КФЙ биналарның милекчеләре мондый йортларны файдаланыла торган суны, җылылык энергиясен, электр энергиясен исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителүен, шулай ук урнаштырылган исәпкә алу җайланмаларының эксплуатациягә кертелүен тәэмин итәргә бурычлы. Бу вакытта КФЙ күрсәтелгән чорга файдаланыла торган суны, җылылык энергиясен, электр энергиясен исәпкә алу буенча күмәк (йортның гомуми) җайланмалар белән, шулай ук файдаланыла торган суны, электр энергиясен исәпкә алу буенча хосусый һәм гомуми (коммуналь фатир өчен) җайланмалар белән тәэмин ителергә тиеш.<br>Төзелеше, үзгәртеп корылышы гамәлгә ашырылганнан соң 2012 елның 1 гыйнварыннан эксплуатациягә кертелүче КФЙ өстәмә рәвештә файдаланыла торган җылылык энергиясен исәпкә алуның хосусый җайланмалары белән тәэмин ителгән булырга тиеш, ә капиталь ремонттан соң 2012 елның 1 гыйнварыннан эксплуатациягә кертелүче йортлар, аларны урнаштыруның техник мөмкинлеге булганда, файдаланыла торган җылылык энергиясен исәпкә алуның хосусый җайланмалары белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмаларының милекчеләре әлеге исәпкә алу җайланмаларының тиешенчә эксплуатацияләнүен, аларның саклануын, үз вакытында алмаштырылуын тәэмин итәргә бурычлы. | | |
| Күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәләрен | КФЙ белән идарә итү шартнамәсендә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:<br>КФЙ аңа карата идарәлек гамәлгә ашырылачак уртак мөлкәтнең составы һәм | РФ ТК 162 ст. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| һәм күпфатирлы йорт белән идарә итүне, шул исәптән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итүче бүтән шартнамәләрне, коммуналь хезмәтләр күрсәтү шартларын үз эченә алган шартнамәләрне һәм күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтеннән файдалану турында шартнамәләрне төзү тәртибе һәм шартлары | мондый йортның адресы;<br>КФЙ белән идарә итү буенча эшләр һәм (яисә) хезмәтләр, КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр һәм эшләр исемлеге, шулай ук идарәче оешма күрсәтә торган коммуналь хезмәтләр исемлеге;<br>шартнамә бәясен, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм коммуналь хезмәтләргә түләү күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук мондый түләүне кертү тәртибе;<br>идарәче оешманың идарә шартнамәсе буенча үз йөкләмәләрен үтәвенә тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе.<br>КФЙ белән идарә итү шартнамәсе шартлары КФЙ биналарның барлык милекчеләре өчен дә бертөрле билгеләнә. | | - |
| Социаль файдаланудагы торак урыннарны наймга бирүчеләргә һәм наймга алучыларга карата таләпләр | Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәсендә катнашучылар РФ ТК 61 статьясының 2 өлешендә, 65 статьясында, 67 статьясының 1 өлешендәге 1, 3 һәм 5 пунктларында, 3 өлешендәге 1-3, 5 һәм 6 пунктларында, 4 өлешендә, 70, 71 һәм 80 статьяларында каралган хокукларга һәм бурычларга ия була, шулай ук РФ ТК 66 һәм 68 статьяларында каралганча җаваплы була.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны карап тоту һәм агымдагы ремонтлау, әгәр дә күрсәтелгән шартнамәдә башкача билгеләнмәсә, наймга бирүченең бурычы булып тора.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсе буенча торак урынны наймга алучының гаилә әгъзаларына наймга алучы белән бергә | РФ ТК 8.1 бүлеге | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | даими рәвештә яшәүче тормыш иптәше, балалары һәм наймга алучының ата-анасы керә.<br>Башка туганнары, хезмәткә яраксыз асрамалар һәм искәрмәле очракларда бүтән гражданнар наймга алучының гаилә әгъзалары булып танылырга мөмкин, әгәр дә алар наймга алучы тарафыннан үзенең гаилә әгъзалары буларак яшәргә кертелгән булса.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынын наймга алучының гаилә әгъзалары мондый шартнамәдә күрсәтелергә тиеш һәм РФ ТК 69 статьясының 2 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән хокукларга һәм бурычларга ия булалар. | | |
| Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләрен һәм торак урыннарының найм шартнамәләрен төзү һәм үтәү | Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсе язмача рәвештә төзелә.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсе наймга бирүченең шушы шартнамә буенча торак урынны бирү турындагы карары нигезендә төзелә.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча наймга бирүче булып түбәндәгеләр тора ала:<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек исеменнән дәүләти яисә муниципаль торак фондының торак урыны милекчесе сыйфатында чыгыш ясарга вәкаләтле булган дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, яисә күрсәтелгән орган тарафыннан вәкаләт бирелгән оешма;<br>хосусый торак фондының торак урыны милекчесе булып торган яисә мондый торак урынның милекчесе тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә җавап бирүче оешма.<br>Социаль файдаланудагы бер наем йортында социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча наймга бирүче булып бары тик бер генә зат тора ала.<br>Торак урынның милекчесе | РФ ТК 8.1 бүлеге | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тарафыннан социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча наймга бирүче булып чыгыш ясау вәкаләте бирелгән оешма әлеге шартнамәләрне төзү вәкаләтләрен шартнамә, ышанычнамә буенча яисә бүтән нигездә бүтән затка тапшыра алмый.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәсе предметы булып социаль файдаланудагы наем йортының торак урыны, бүлмәләрдән (фатир өлешләреннән) тыш, яисә социаль файдаланудагы наем йорты булып торучы торак йорт торырга мөмкин.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәсе кимендә бер елга, ләкин иң күбе ун елга төзелә.<br>Социаль файдаланудагы торак фонды торак урынының найм шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын карап тоту һәм агымдагы ремонтлау, әгәр дә күрсәтелгән шартнамәдә башкача билгеләнмәсә, наймга бирүченең бурычы булып тора.<br>Наймга бирүченең социаль файдаланудагы торак фонды торак урынын мондый торак урынның найм шартнамәсе буенча яисә аның бер өлешен поднаемга яисә түләүсез файдалану шартнамәсе буенча тапшыруы һәм мондый торак урынны алмаштыруы рөхсәт ителми. | | |
| ТР ДТИ компетенциясе чикләрендә капиталь ремонт фондлары төзүне тикшереп тору | Махсус счет хуҗаы Инспекциягә түбәндәге белешмәләрне тапшырырга тиеш:<br>1) тиешле КФЙ биналарның милекчеләре сайлаган капиталь ремонт фонды төзү ысулы турында хәбәрнамә, түбәндәгеләрне теркәп:<br>а) биналарның милекчеләренең гомуми җыелышыннан РФ ТК 170 статьясының 3 һәм 4 өлешләрендә каралган карарларны кабул итүләре хакында беркетмә күчермәләре;<br>б) махсус счет ачу турында банк белешмәләре;<br>в) биналарның милекчеләренең уртак җыелышыннан КФЙ белән идарә итү ысулын сайлау турында беркетмәләрнең күчермәләре; | РФ ТК 170, 172 ст.<br><br>52-ТРЗ номерлы Законның 12 ст.<br><br>ТР ДТИ «Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез | Инспекция компетенциясе кысаларында капиталь ремонт фондлары төзүне тикшереп тору |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | г) КФЙ турында мәгълүматлар (катлар саны, КФЙ гомуми мәйданы, КФЙ торак урыннар мәйданы, фатирлар саны, КФЙ теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы);<br>2) капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында күчерелгән акча күләме турында мәгълүмат;<br>2.1) капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә күчерелгән акча күләме турында мәгълүмат;<br>2.2) махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акча күләме турында мәгълүмат;<br>3) махсус счетта акчаның калдык өлеше турында мәгълүмат;<br>4) капиталь ремонт уздыруга займ шартнамәсе һәм (яисә) кредит шартнамәсе төзү турында мәгълүмат, мондый шартнамәләрнең таныкланган күчермәләрен теркәп.<br>Төбәк операторы Инспекциягә биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын төбәк операторы счетында, счетларында төзегән КФЙ турында, шулай ук мондый КФЙ биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр күчерелүе турында түбәндәге мәгълүматларны тапшырырга тиеш:<br>1) биналарның милекчеләренең уртак җыелышыннан КФЙ белән идарә итү ысулын сайлау турында беркетмәләрнең күчермәләре;<br>2) КФЙ турында мәгълүматлар (катлар саны, КФЙ гомуми мәйданы, КФЙ торак урыннар мәйданы, фатирлар саны, КФЙ теркәлгән гражданнар саны, эксплуатациягә кертү елы, соңгы мәртәбә капиталь ремонт уздыру елы);<br>3) биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган капиталь ремонт фонды төзү ысулы турында хәбәрнамә;<br>4) капиталь ремонт фонды төзү ысулын сайлау турында биналарның милекчеләренең гомуми җыелышыннан беркетмәләрнең күчермәләре;<br>5) реквизитларын күрсәтеп, счет, төбәк операторы счетларын ачу турында белешмә; | оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан ТР ДТИ белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 151 номерлы боерыгы (алга таба – ТР ДТИ 151 номерлы боерыгы) | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6) биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка төбәк операторы счетына, счетларына кертемнәрнең күчерелүен раслаучы документлар;<br>7) төбәк операторы счетында, счетларында акчаның калдык өлеше турында мәгълүмат.<br>3. Инспекция РФ ТК 172 статьясының 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрнең реестрын, махсус счетлар реестрын алып бара, җирле үзидарә органына һәм төбәк операторына биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондларын төзү ысулын сайламаган һәм (яисә) аны тормышка ашырмаган КФЙ турында мәгълүмат җиткерә. | | |
| ТР ДТИ компетенциясе кысаларында төбәк операторының эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе | Инспекция дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан милекчелек формаларына бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга карата федераль законнар нигезендә билгеләнгән таләпләрне, шул исәптән капиталь ремонт фондлары төзүгә, төбәк операторы булдыруга һәм аның эшчәнлегенә карата таләпләрне бозуларны кисәтүгә, ачыклауга һәм тыюга юнәлдерелгән эшчәнлекне федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк операторының эшчәнлеге билгеләнгән таләпләргә җавап бирүен контрольдә тоту тәртибе» 2015 елның 15 мартындагы 195 номерлы карары (алга таба – ТР МК 195 номерлы карары) белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.<br>Әгәр КФЙ биналарның милекчеләре РФ ТК 170 ст. 5 һәм 5.1 өлешләрендә билгеләнгән чорда капиталь ремонт фонды төзү ысулын сайламаса яисә алар сайлаган ысул РФ ТК 170 ст. 5 һәм 5.1 өлешләрендә билгеләнгән чорда тормышка ашырылмаса һәм РФ ТК 189 статьясының 7 өлешендә каралган очракларда җирле үзидарә органы РФ ТК 172 статьясының 4 өлешендә | РФ ТК 170 ст. 7 өл., 186 ст. 1 өл., 172 ст, 52-ТРЗ номерлы Закон, ТР МК 195 номерлы карары. | Җирле үзидарә органы карары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | каралган мәгълүматны Инспекциядән алган көннән башлап бер ай эчендә мондый йортка карата төбәк операторы счетында капиталь ремонт фонды төзү турында карар кабул итә. | | |
| Коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм методларына, шулай ук коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалануның билгеләнгән нормативы күләменең нигезле булу-булмавына карата таләпләр үтәлеше | Коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм методларына, шулай ук коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалануның билгеләнгән нормативы күләменең нигезле булу-булмавына карата таләпләр үтәлеше.<br>Файдалану нормативлары түбәндәгечә билгеләнә:<br>торак урыннарда күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә карата, – күрсәтелүче коммуналь хезмәтләрнең КФЙ яисә торак йортның төзекләндерелү дәрәҗәсе белән билгеләнә торган һәр төре буенча;<br>КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту максатларында кулланыла торган коммуналь ресурсларга карата, – файдаланыла торган коммуналь ресурсларның (җылылык энергиясеннән кала) КФЙ төзекләндерелү дәрәҗәсе, шулай ук уртак мөлкәт составына кертелгән ресурс куллану җайланмалары һәм җиһазлары булуы белән билгеләнә торган һәр төре буенча;<br>җир кишәрлегеннән һәм ишегалды корылмаларыннан файдаланганда күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләргә карата, – алардан файдалану юнәлешләрен исәпкә алып, салкын су, электр энергиясе белән тәэмин итү һәм җылыту буенча коммуналь хезмәтләргә карата.<br>Торак урыннарда коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары һәм КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслардан файдалану нормативлары аналогик конструктив һәм техник параметрларга, төзекләндерелү дәрәҗәсенә ия булган, шулай ук аналогик климат шартларында урнашкан КФЙ һәм торак йортлар өчен | РФ ТК 20 ст.<br><br>РФ Хөкүмәтенең 306 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бердәй билгеләнә. Конструктив һәм техник параметрларда, төзекләндерелү дәрәҗәсендә, шулай ук КФЙ яисә торак йортлар урнашкан климат шартларында аермалыклар булганда, коммуналь хезмәтләрдән файдалануның күрсәтелгән нормативлары КФЙ һәм торак йортларның категорияләренә карап дифференциацияләнә.<br>Торак урыннарда коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары һәм КФЙ уртак мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслардан файдалану нормативлары коммуналь хезмәтләрнең сыйфатына карата Россия Федерациясенең закон һәм бүтән норматив хокукый актларында каралган таләпләргә нигезләнеп билгеләнә. | | |

3.2. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуны кисәтү, зарури таләпләр бозылуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Инспекция ел саен үзе раслаган бозуларны профилактикалау программасы нигезендә зарури таләпләр бозылуны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра.

3.3. Инспекциядә зарури таләпләрне бозарга әзерләнүләр яисә бозу билгеләре турында юридик затлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын тормышка ашыру барышында алынган яисә килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) бәян ителгән белешмәләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар булганда, әгәр зарури таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка китерүе яисә күрсәтелгән нәтиҗәләрнең турыдан-туры куркынычын барлыкка китерүе турында дәлилләнгән белешмәләр булмаса һәм, әгәр дә юридик зат элегрәк тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, Инспекция юридик затка зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда Инспекциягә хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны Инспекция тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Инспекциягә мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары белән расланган

Заруриі таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, мондый кисәтүгә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ КҮЗӘТЧЕЛЕК ОБЪЕКТЫ ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен күзәтчелек объекты тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен күзәтчелек объекты тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү уздырганда күзәтчелек объекты тарафыннан тапшырыла торган документлар | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Юридик затның яисә шәхси эшкуарның гамәлгә кую һәм теркәүгә алу документлары | РФ ГК 52 ст.;<br>«Акционерлык җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст.;<br>«Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль законның 12 ст.;<br>Федераль салым хезмәтенең 2012 елның 25 гыйнварындагы ММВ-7-6/25@ номерлы һәм 2016 елның 12 сентябрендәге ММВ-7-14/481@ номерлы боерыклары. |
| 2. Гражданинның шәхесен таныклаучы документлар (шәхси эшкуарлар өчен) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданины паспорты, Россия Федерациясе гражданины паспортының бланк үрнәге һәм тасвирламасы турында нигезләмә раслау турында» 1997 елның 8 июлендәге 828 номерлы карары |
| 3. Юридик затның, шәхси эшкуарның яисә гражданинның мәнфәгатьләрен белдерүче затның вәкаләтләрен раслаучы документлар | |
| 4. Җитешсезлекләрне оператив бетерүгә халыктан заявкаларны исәпкә алу журналы | ПиН 5 нче кушымтасы |

| | |
|---|---|
| 5. Күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе | РФ ТК 162 ст. |
| 6. Алдагы елда идарә итү шартнамәсен үтәү турында хисап | РФ ТК 162 ст. 11 өл. |
| 7. Торак йортлар белән идарә итүче оешманың коммуналь ресурсларны җиткерүчеләр белән шартнамәсе | РФ Төбәк үсеше министрлыгының «Коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең ресурс белән тәэмин итү оешмалары белән шартнамәләр төзүе турында» 2007 елның 29 ноябрендәге 21492-СК/07 боерыгы |
| 8. Юридик зат мәнфәгатьләрен белдерүгә ышанычнамә | |
| 9. Юридик затның, шәхси эшкуарның дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнары тарафыннан уздырыла торган тикшерүләрне исәпкә алу журналы | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгына 4 нче кушымта |
| 10. Торак йортны эксплуатацияләүгә бәйле техник документация, (йортның проекты, техник паспорты, йортны планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр актлары, җылыту буенча йорт эчендәге системаларны юдырту, һава кудырту актлары, йортның кышкы чорда файдалануга әзерлек паспорты, ремонт эшләрен башкару планнары-графиклары һ.б.) | ПиН |
| 11. Махсус счет хуҗасы Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырырга бурычлы булган белешмәләр | ТР ДТИ 151 номерлы боерыгы |
| 12. Төбәк операторы Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырырга бурычлы булган, биналарының милекчеләре төбәк операторы счетында, счетларында капиталь ремонт фонды төзүче күпфатирлы йортлар турында, мондый күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр күчерелүе турында белешмәләр | ТР ДТИ 151 номерлы боерыгы |
| 13. Торак урынны карап тоту һәм | Россия Төзелеш министрлыгының «Торак урынны |

| | |
|---|---|
| ремонтлау һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү кертү өчен түләү документы формасы | карап тоту һәм ремонтлау һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү кертү өчен түләү документының үрнәк формасын һәм аны тутыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 924/пр номерлы боерыгы |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ КЫСАЛАРЫНДА ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Дәүләт функциясен үтәү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

тикшерүләрнең еллык планын төзү һәм раслау;

планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыруны оештыру;

тикшерү уздыру (планлы документар, планлы урынга чыгып, планнан тыш документар, планнан тыш урынга чыгып);

тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

тикшерүләрне уздырганда ачыкланган бозу фактларына карата чаралар күрү;

юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын гамәлгә ашыру;

системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау.

5.2. Дәүләт функциясен үтәү буенча блок-схема шушы Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелде.

5.3. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

### «ЕЛЛЫК ТИКШЕРҮЛӘР ПЛАНЫН ТӨЗҮ ҺӘМ РАСЛАУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.4. Административ процедураны башлап җибәрү өчен еллык тикшерүләр планын әзерләү вакыты килеп җитү нигез булып тора.

5.5. Дәүләт хакимияте органнарын, җирле үзидарә органнарын, юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерүләрнең еллык планнары проектлары Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы, зона торак инспекцияләре башлыклары, Инспекциянең Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы тарафыннан төзелә.

Бу вакытта билгеләнгән тәртиптә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә планны төзү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматлар (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы) соратып алына.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 1 августына кадәр.

5.6. Тикшерүләрнең формалаштырылган планнары проектлары тикшерүләрнең җыелма планын төзү өчен Инспекциянең Хокук идарәсенә тапшырыла.

Тикшерүләрнең җыелма планы төзелгәннән соң Инспекциянең Хокук идарәсе аны Инспекция башлыгы белән килештерә һәм тикшерүләрнең еллык план проектын прокуратура органнарына җибәрә.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 1 сентябренә кадәр.

5.7. Тикшерүләрнең еллык планы проектын караганнан соң һәм прокуратура органнары тарафыннан тәкъдимнәр кертелгәч, Инспекциянең Хокук идарәсе прокуратура органнарыннан килгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, тикшерүләрнең еллык план проектына төзәтмәләр кертә һәм аны раслау өчен Инспекция башлыгына җибәрә.

Тикшерүләр планы Инспекция башлыгы тарафыннан расланганнан соң, Инспекциянең Хокук идарәсе аны билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнарына җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүләрнең расланган планын прокуратура органнарына җибәрү – планлы тикшерүләр уздырылган елдан соңгы елның 1 ноябренә кадәр.

5.8. Әлеге административ процедураны үтәү өчен Инспекциянең Хокук идарәсе башлыгы, Инспекциянең территориаль органнары җитәкчеләре җаваплы була: Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы, зона торак инспекцияләре башлыклары, Инспекциянең Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы.

5.9. Күзәтчелек объектларын планлы тикшерүне еллык тикшерүләр планына кертү өчен әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.10. Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр өч елга ике һәм аннан күбрәк мәртәбә үткәрелергә мөмкин. Мондый эшчәнлек төрләренең исемлеге һәм аларны планлы тикшерүләр ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнар нигезендә энергетика тикшерүен уздыру алар өчен зарури булган затлар тарафыннан билгеләнгән чорларда энергетика тикшерүен уздыруга карата таләпләрнең үтәлүен планлы тикшерүләр энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнардагы таләпләр нигезендә мәҗбүри энергетика тикшерүен уздыру өчен билгеләнгән чор тәмамлана торган елдан соң килүче елда уздырылырга тиеш.

5.11. Юридик затларны, шәхси эшкуарларны – үзкөйләнешле оешмаларның әгъзаларын планлы тикшерүләр үзкөйләнешле оешманың гомуми исәбендә иң күбе ун процентына карата һәм үзкөйләнешле оешманың кимендә ике әгъзасына карата планлы тикшерүләр уздыруның еллык планы нигезендә уздырыла, әгәр федераль законнарда башкача каралмаса.

5.12. РФ ТК 20 статьясының 4.3 өлеше нигезендә төбәк операторлары эшчәнлеген тикшерү планлы тикшерүләр уздыруның еллык планын төземичә уздырыла.

5.13. Тикшерүләрнең еллык планнарында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

эшчәнлекләре планлы тикшерүгә тиешле юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) аталышы, шәхси эшкуарларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыннары яисә шәхси эшкуарларның эшчәнлекләре фактта гамәлгә ашырылган урыннары;

һәр планлы тикшерүне уздыру максаты һәм нигезләре;

һәр планлы тикшерүне уздыра башлау датасы һәм чорлары;

билгеле бер планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы дәүләт күзәтчелеге органы (Инспекциянең) исеме. Планлы тикшерүне дәүләт күзәтчелеге органнары белән бергә уздырганда мондый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның исемнәре күрсәтелә.

5.14. «Еллык тикшерүләр планын төзү һәм раслау» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе булып расланган тикшерүләр планы тора.

5.15. Тикшерүләр планын эшләгәндә һәм раслаганда карарлар кабул итү критерийлары булып аны рәсмиләштерү чорларының һәм тәртибенең, аның формасының гамәлдәге законнарга туры килүе тора.

5.16. Тикшерүләрнең расланган планы, аны «Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, мәнфәгатьле затлар игътибарына җиткерелә.

## «ПЛАНЛЫ ҺӘМ ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУНЫ ОЕШТЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.17. Еллык тикшерүләр планы нигезендә планлы тикшерү уздыру вакытларының килеп җитүе яисә планнан тыш тикшерү уздыру өчен әлеге Регламентның 2.14 пунктында каралаган нигезләрнең булуы административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Планнан тыш тикшерү уздыру өчен шушы Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта, Инспекциянең килгән мөрәҗәгатьне, гаризаны яисә мәгълүматны карап тикшерүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи заты шушы Регламентның 2.15-2.20 пунктларында бәян ителгән таләпләр нигезендә түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) мөрәҗәгать итүче затны ачыклау буенча гакыллы чаралар күрә;

2) шуңа охшаш, элегрәк килгән мөрәҗәгатьләрнең һәм гаризаларның нәтиҗәләрен, мәгълүматларны, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләрен карап тикшерә;

3) килгән мәгълүматка башлангыч тикшерүне үткәрә;

4) зарурлык булганда юридик зат, шәхси эшкуар белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат тапшыру һәм Инспекция таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын үткәрә;

5) әлеге Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилле йогынты акты әзерли.

5.18. «Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыруны оештыру» административ процедурасы түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) тикшерү уздыру турында карар кабул итү, җаваплы башкаручыны билгеләү;

2) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү уздыру турында әмернамәсен әзерләү;

3) күзәтчелек объектына тикшерү уздыру турында хәбәр итү.

## ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТҮ, ҖАВАПЛЫ БАШКАРУЧЫНЫ БИЛГЕЛӘҮ

5.19. Тикшерүләрнең еллык планы яисә Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) планнан тыш тикшерү уздыру йөкләмәсе нигезендә Инспекциянең структур бүлекчәсе башлыгы:

1) күзәтчелек объектына тикшерү уздыру өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) (алга таба – җаваплы башкаручы, дәүләт торак инспекторы) билгели, бу вакытта карар кабул итү өчен критерий вазыйфаи затның тикшерүләр уздыруга вәкаләте булудан гыйбарәт;

2) зарурлык булган очракта үзләренә карата тикшерү уздырыла торган юридик зат, шәхси эшкуар белән гражданый-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затның аффилир затлары булып тормаган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертларны, Россия Федерациясенең илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында законнары нигезендә аккредитацияләнгән эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү вакыты:

планлы тикшерү уздырганда – тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр биш эш көненнән соңга калмыйча яисә тикшерүләрнең еллык планы төзелгәннән соң турыдан-туры;

планнан тыш тикшерү уздырганда – Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 һәм 4 пунктчаларда күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы йөкләмәсе кабул ителгән көнне.

## ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА ӘМЕРНАМӘ ӘЗЕРЛӘҮ

5.20. Тикшерү уздыру турында карар Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының), Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган типик үрнәккә (шушы Регламентның 5 нче кушымтасы) туры китереп, тикшерү уздыру турындагы әмернамәсе белән рәсмиләштерелә.

Җаваплы башкаручы:

1) күзәтчелек объектына тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) әмернамәсе проектын әзерли;

2) әмернамә проектын Бүлек башлыгы белән килештерә (имза сала);

3) әмернамә проектын имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты:

планлы тикшерү уздырганда – тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр дүрт эш

көненнән соңга калмыйча;

планнан тыш тикшерү уздырганда – тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр ике эш көненнән соңга калмыйча;

294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 12 өлеше нигезендә кичекмәстән планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру зарурлыгы булганда – тикшерү уздыру өчен нигез булган тиешле документлар килгән көнне.

5.21. Тикшерү уздыру турындагы әмернамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Инспекциянең исеме, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төре (төрләре);

2) тикшерү уздыруга вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү уздыру өчен җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

3) үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның аталышы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яисә шәхси эшкуарларның фактта эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыннары;

4) тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны уздыру вакыты;

5) тикшерү уздыруның хокукый нигезләре;

6) тикшерелергә тиешле зарури таләпләр, шул исәптән тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлегенең) реквизитлары, әгәр дә планлы тикшерү уздырганда тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга тиешле булса;

7) тикшерү уздыруның максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зарури булган контрольлек чараларын үткәрү вакытлары һәм аларның исемлеге;

8) төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге;

9) тикшерү уздыруның максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

10) тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары;

11) бүтән белешмәләр, әгәр дә бу хәл Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) әмернамәсенең типик рәвешендә каралган булса.

5.22. Планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигез булып әлеге Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасының «а» һәм «б» пункт өлешләрендә күрсәтелгән нигез торган очракта, җаваплы башкаручы:

1) планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча прокуратура органы белән килештерү турында гариза әзерли;

2) аны Инспекция башлыгыннан (башлык урынбасарыннан) имзалата;

3) имзалатканнан соң Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында әмернамәсе күчермәсен һәм аны уздыру өчен нигез булып хезмәт иткән белешмәләрне үз эченә алган документларны кушып куя;

4) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын

буенча прокуратура органына тапшыра яисә кулга тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат итеп яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

Үтәү вакыты:

гариза рәсмиләштерү – планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында әмернамә рәсмиләштерү белән бер үк вакытта;

гаризаны прокуратура органына җибәрү – әмернамәгә имза салынган көнне.

Юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планнан тыш урынга чыгып тикшерүләр уздыруны прокуратура органнарында килештерү Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру турында» 2009 елның 27 мартындагы 93 номерлы боерыгы белән расланган тәртипкә туры китереп гамәлгә ашырыла.

Инспекциянең юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерүе турында гариза Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган типик формада рәсмиләштерелә.

Шушы Регламентның 2.14 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерүләр, төбәк операторларына карата планнан тыш тикшерүләр прокуратура органнары белән килештереп тормыйча уздырыла.

5.23. Әгәр планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигез булып гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеручы кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зыян салынуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләрнең барлыкка килүе, зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең бозуларның ачыклануы торса, мондый бозуларны кылынган вакытында кичекмәстән чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә Инспекция 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 6 һәм 7 өлешләрендә каралган документларны прокуратура органнарына егерме дүрт сәгать эчендә җибәрү юлы белән, контрольлек чаралары уздырылуы турында прокуратура органнарына хәбәр итеп, планнан тыш урынга чыгып тикшерүне кичекмәстән уздыра башларга хокуклы. Бу очракта прокурор яисә аның урынбасары планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны килештерү турында карарны тиешле документлар килгән көнне кабул итә.

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ОБЪЕКТЫНА ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

5.24. Җаваплы башкаручы планлы тикшерүне уздыра башлау турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әмернамәсенең күчермәсен кулга тапшыру турында хәбәрләмә белән почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән һәм

(яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Инспекциягә элегрәк тапшырылган булса, яисә мөмкин булган бүтән ысул белән планлы тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү уздыру турында хәбәр итү – тикшерүне үткәрә башларга кимендә өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

5.25. Җаваплы башкаручы күзәтчелек объектына урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында, шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2, 3, 5 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган планнан тыш урынга чыгып тикшерүдән кала, мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Инспекциягә элегрәк тапшырылган булса.

Үтәү вакыты: күзәтчелек объектына планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздырылуы турында хәбәр итү – тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән соңга калмыйча.

5.26. Шушы Регламентның 2.14 пунктының 2, 3, 5 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрдә планнан тыш тикшерүләр, төбәк операторларына карата планнан тыш тикшерүләр күзәтчелек объектына планнан тыш тикшерү уздырылуы турында алдан хәбәр итмичә уздырыла.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларына планлы тикшерү уздырылган очракта җаваплы башкаручы үзкөйләнешле оешмага планлы тикшерүне уздырганда катнашу яисә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында хәбәр итә.

5.27. «Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыруны оештыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

1) тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларны күрсәтеп, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү уздыру турында әмернамә;

2) күзәтчелек объектына тикшерү уздыру турында хәбәр итү;

3) административ процедура нәтиҗәләре турында бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән белешмәләр.

## «(ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР, ПЛАНЛЫ УРЫНГА ЧЫГЫП, ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР, ПЛАННАН ТЫШ УРЫНГА ЧЫГЫП) ТИКШЕРҮ УЗДЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.28. Административ процедураны уздыра башлау өчен Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү уздыру турында әмернамәсе нигез булып тора.

Тикшерү бары тик тикшерү уздыру турында әмернамәдә күрсәтелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гына уздырыла ала.

Конкрет тикшерүне уздыруга Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әмернамәсендә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тикшерүне уздыру өчен җаваплы була.

5.29. Планлы документар, планнан тыш документар тикшерүләр административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

1) Инспекция карамагында булган күзәтчелек объекты документларын карау;

2) белешмәләрнең төгәл булмавы ачыкланган очракта (тапшырылган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар булуы ачыкланганда) күзәтчелек объекты адресына дәлилләнгән гарызнамә (язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбен) рәсмиләштерү һәм җибәрү;

3) күзәтчелек объекты тапшырган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карау;

4) зарури таләпләр бозылу билгеләре ачыкланган очракта, урынга чыгып тикшерү уздыруның инициаторы булу.

5.30. Планлы документар, планнан тыш документар тикшерүләр административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

1) контрольлек чараларын уздыра башлау алдыннан Инспекциянең вазыйфаи затлары гамәлләренә карата таләпләрне үтәп, тикшерү уздыру урынына килү;

2) күзәтчелек объекты тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүен тикшерү, зарури таләпләрнең бозылу очракларын яисә андый очракларның булмавын ачыклау.

Җаваплы башкаручы тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

Салым серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән торучы документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорату тиешле белешмәләрне тикшерүнең юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү фактын билгеләү зарурлыгы белән аңлатылган һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырылуы федераль законда каралган булуы шарты белән рөхсәт ителә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документларны һәм (яисә) мәгълүматларны бирү, аларны ачу, шул исәптән, 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, алар белән таныштыру Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм законда саклана торган бүтән сер турында законнарындагы таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮ

5.31. Планлы тикшерүнең предметы булып күзәтчелек объектының эшчәнлекне гамәлгә ашырганда белдерелә торган зарури таләпләр җыелмасын

үтәве, шулай ук эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә бәян ителгән белешмәләрнең зарури таләпләргә туры килүе тора.

5.32. Күзәтчелек объектына планлы тикшерү расланган еллык тикшерүләр планы нигезендә уздырыла.

ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ

5.33. Планнан тыш тикшерүнең предметы булып юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлекне гамәлгә ашырганда зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәве, Инспекция күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеручы кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга зыян салынуны чикләү, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләрнең барлыкка килүен кисәтү буенча, мондый зыян нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча чаралар уздырылуы тора.

5.34. Әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәне үтәү вакыты узу планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып торса, ул очракта мондый тикшерүнең предметы булып бары тик Инспекция биргән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.

ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ

5.35. Документар тикшерү предметы булып күзәтчелек объекты документларда аларның оешу-хокук рәвешен, хокукларын һәм бурычларын билгели торган белешмәләр, үзләренең эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм аларның зарури таләпләрне, Инспекция күрсәтмәләрен һәм карарларын үтәве белән бәйле документлар тора.

5.36. Документар тикшерү (планлысы да, планнан тыш та) Инспекция, аның территориаль органнары урнашкан урын буенча уздырыла.

5.37. Документар тикшерүне уздырганда җаваплы башкаручы тарафыннан иң беренче чиратта күзәтчелек объектының Инспекция карамагында булган документлары, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә, алдагы тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм әлеге күзәтчелек объектларына карата гамәлгә ашырылган төбәк дәүләт торак күзәтчелеге нәтиҗәләре турында документлар карала.

5.38. Җаваплы башкаручы:

1) Инспекциядә булган документлардагы белешмәләрнең төгәл булу-булмавын бәяли;

2) документлардагы белешмәләрне күзәтчелек объекты эшчәнлегенең

билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе предметына бәяли.

Әгәр документлардагы белешмәләрнең төгәл булу-булмавында нигезле шик барлыкка китерсә, яисә әлеге белешмәләр юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлгәнлеген бәяләргә ирек бирмәсә, әгәр Инспекциягә тапшырылган һәм аның карамагында булган документларда хаталар ачыкланса һәм (яисә) каршылыклар, белешмәләрнең туры килмәү очраклары булса, җаваплы башкаручы:

1) юридик зат, шәхси эшкуар адресына белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар һәм ун эш көне эчендә кирәкле аңлатмаларны язмача рәвештә яисә карау өчен киркәле бүтән документларны тапшыру таләбе белән, хат (дәлилле гарызнамә) әзерли;

2) хатка Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) кул куйганнан соң, аны күзәтчелек объекты адресына заказлы хат итеп, кулга тапшыру турында хәбәрнамә белән, яисә мөмкин булган башка ысул белән җибәрә.

Җаваплы башкаручы тикшерү уздыру турында әмернамә кабул ителгәннән соң шушы Регламентның 4 бүлегендәге 2 нче таблицада китерелгән исемлеккә туры китереп, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматларны күзәтчелек объектыннан соратырга хокуклы.

5.39. Җирле үзидарә органыннан яисә җирле үзидарә органы вазыйфаи затыннан мәгълүмат бирү турында Инспекция гарызнамәсе җирле үзидарә органы җитәкчесенә яисә җирле үзидарә органының вазыйфаи затына аларның вәкаләтләрен исәпкә алып җибәрелә. Гарызнамәне турыдан-туры карау гарызнамәдәге мәсьәләләрне карауга компетентлы булган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары тарафыннан гарызнамә буенча Инспекциягә мәгълүматлар бирү өчен билгеләнә торган чор кимендә 10 эш көне тәшкил итә.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тууга, шулай ук гражданнарның хокуклары массакүләм бозылуга китереп чыгара торган Россия Федерациясе законнары бозылу фактлары билгеләнгән очракларда мәгълүмат тапшыру чорын кыскарту рөхсәт ителә.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, әгәр бу мәгълүмат элегрәк бирелгән булса яисә массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырылган булса яки «Интернет» челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылган булса, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары гарызнамәсе буенча мәгълүматны бирмәскә хокуклы. Бу вакытта җирле үзидарә органы, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гарызнамәгә җавапта рәсми рәвештә бастырылган чыганак яисә тиешле мәгълүматны урнаштыру чыганагы турында хәбәр итә.

Җаваплы башкаручы күзәтчелек объекты җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында бүтән дәүләт органнарыннан, оешмалардан алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштыра.

Үтәү вакыты: тикшерүне уздыра башлаган көнгә кадәр биш эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: күзәтчелек объекты адресына документлар тапшыру таләбе белән җибәрелгән хат (дәлилле гарызнамә).

5.40. Күзәтчелек объекты билгеләнгән чорларда Инспекциягә гарызнамәдә күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм күзәтчелек объекты җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Күзәтчелек объекты гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

Күзәтчелек объектының җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле тикшерү уздырылганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Инспекциягә үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Инспекциягә тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

5.41. Җаваплы башкаручы күзәтчелек объекты тапшырган документларны һәм (яки) аңлатмаларны карый. Әгәр дә тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда, шушы Регламентның 3 бүлегендәге 1 нче таблицада күрсәтелгән зарури таләпләренең бозылу билгеләре ачыкланса, җаваплы башкаручы, Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) урынга чыгып тикшерү үткәрү турында әмернамәсе проектын әзерләү юлы белән, урынга чыгып тикшерү уздыруның инициаторы була. Урынга чыгып тикшерү уздырганда күзәтчелек объектыннан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.

Урынга чыгып тикшерү шушы Регламентның «Урынга чыгып тикшерү» бүлекчәсендә китерелгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Урынга чыгып тикшерү уздыру турында карарны Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) кабул итә.

Урынга чыгып тикшерү уздыру зарурлыгы турында карар кабул итү өчен критерий булып күзәтчелек объекты тапшырган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карау барышында ачыкланган, урынга чыгып тикшерү уздыру өчен нигез булып хезмәт итүче зарури таләпләрнең бозылу билгеләре тора.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны һәм (яисә) документларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан күзәтчелек объекты тапшырган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карау; зарурлык булганда – урынга чыгып тикшерү уздыру турында әмернамә проекты.

## УРЫНГА ЧЫГЫП ТИКШЕРҮ

5.42. Урынга чыгып тикшерү предметы булып күзәтчелек объекты документларындагы белешмәләр, шулай ук андагы хезмәткәрләрнең туры килүе, эшчәнлекне гамәлгә ашырганда күзәтчелек объектлары тарафыннан файдаланылучы территорияләрнең, биналарның, корылмаларның, бүлмәләрнең, җайланмаларның, шуңа охшаш объектларның торышы, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәтләр һәм алар тарафыннан зарури таләпләрне үтәү буенча күрелә торган

чаралар тора.

5.43. Урынга чыгып тикшерү (планлысы да, планнан тыш та) юридик зат урнашкан урын, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча һәм (яисә) аларның эшчәнлекләре фактта гамәлгә ашырылган урын буенча уздырыла.

5.44. Урынга чыгып тикшерү документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракларда уздырыла:

1) Инспекция карамагында булган күзәтчелек объекты документларындагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуына инану;

2) күзәтчелек объекты эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

5.45. Җаваплы башкаручылар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре күзәтчелек объектына килеп җитү белән тикшерүне түбәндәгечә башлыйлар:

1) хезмәт таныклыкларын күрсәтеп һәм күзәтчелек объекты җитәкчесенә яисә бүтән вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздыру турында әмернамәнең мөһер белән таныкланган күчермәсен имза куйдыртып тапшырып;

2) күзәтчелек объекты җитәкчесен яисә бүтән вазыйфаи затын, вәкаләтле вәкилен Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) урынга чыгып тикшерүне билгеләү турында боерыгы белән мәҗбүри таныштырып;

3) күзәтчелек объекты җитәкчесенә яисә вазыйфаи затына, аның вәкаләтле вәкиленә урынга чыгып тикшерү уздыручы затларның вәкаләтләре, шулай ук урынга чыгып уздырылган тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып тикшерү уздыру өчен җәлеп ителүче экспертларның составы, эксперт оешмалары вәкилләре, аны уздыру вакытлары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырып.

5.46. Күзәтчелек объектының җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле Инспекциянең урынга чыгып тикшерү уздыручы вазыйфаи затларына урынга чыгып тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр дә мондый документлар урынга чыгып тикшерү алдыннан булган документар тикшерү барышында тапшырылмаган булса, шулай ук урынга чыгып тикшерү уздыручы вазыйфаи затларга һәм тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт оешмалары вәкилләренә күзәтчелек объекты тарафыннан эшчәнлеген гамәлгә ашырганда файдаланылучы территориягә, бинага, корылмага, төзелмәгә, бүлмәнә, файдаланыла торган җайланмага, шуңа охшаш объектларга үтеп керүне тәэмин итәргә тиеш.

5.47. Җаваплы башкаручы күзәтчелек объекты эшчәнлегенең шушы Регламентның 3 бүлегендәге 1 нче таблицасында китерелгән зарури таләпләргә җавап бирү-бирмәвен бәяли, шул исәптән күзәтчелек буенча түбәндәге чараларны уздыра:

1) торак фонды объектларын карый (тикшерә);

2) төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм кирәкле бүтән документлар белән таныша;

3) торак законнары, энергия саклау турында законнар һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар өлкәсендә нормативларның, дәүләт стандартларының һәм бүтән норматив документларның, милекчелек формасына бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга карата таләпләрнең үтәлүен тикшерә;

4) зарури таләпләрнең бозылу фактлары ачыкланган очракта, гамәлдәге законнарда каралган чараларны күрә.

5.48. «Тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү вакыты – әлеге Регламентның 2.10 пунктындагы таләпләргә туры китереп.

5.49. Әгәр дә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Инспекция, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.50. «Тикшерү уздыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

1) тикшерү уздыру турында әмернамә нигезендә контрольлек чаралары уздыру;

2) зарури таләпләрнең бозылуның ачыкланган очраклары булу яисә булмау.

## «ТИКШЕРҮЛӘРНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.51. Административ процедураны уздыра башлау өчен нигез булып тикшерүне тәмамлау тора.

5.52. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы:

1) ике нөсхәдә тикшерү акты төзи (тикшерү актының типик үрнәге шушы Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелде);

2) зарури таләпләр бозылуны ачыклаган очракта, тикшерү актында ачыкланган бозуларның арлык очракларын терки һәм шушы Регламентның 5.63-5.70 пунктлары нигезендә ачыкланган бозуларны бетерү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләрне бирә, алар тикшерү актына кушымта булып килә (һәр бозу буенча аерым күрсәтмә);

3) күзәтчелек объектының зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмалар сората;

4) тикшерү актына үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләрен яисә бәяләмәләрен, күзәтчелек объектының зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмаларны, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документларны яисә аларның күчермәләрен кушып куя;

5) тикшерүне уздырган вазыйфаи затлар белән бергә 2 нөсхәдә тикшерү актына кул куя;

Үтәү вакыты: тикшерү актын рәсмиләштерү – тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры;

6) тикшерү актының бер нөсхәсен кушымталарның күчермәләре белән бергә күзәтчелек объекты җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында тикшерү актында кул куйдырып тапшыра;

Үтәү вакыты: актка кул куйганнан соң турыдан-туры;

7) күзәтчелек объектының җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче затның тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында язу бирүдән баш тартуы очрагында, тикшерү актының кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелүен тәэмин итә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты күзәтчелек объекты җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә;

Үтәү вакыты: актка кул куйганнан соң турыдан-туры;

8) тикшерү актының икенче нөсхәсенә тиешле язуны терки, аңа почта заказ белән җибәрелгән хатның кулга тапшырылуы турында хәбәрнамәне яисә электрон рәвештә җибәрелгән актны алу турында хәбәрнамәне куша һәм аны кушымталары белән бергә эшкә теген куя;

Үтәү вакыты: тикшерү актын почта аша заказлы хат итеп җибәргәннән соң турыдан-туры.

9) РФ КоАП каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, шушы Регламентның 5.71-5.77 пунктлары нигезендә административ хокук бозу турында беркетмә төзи.

5.53. Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм күзәтчелек объекты җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда хәбәрнамә һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының Инспекциядә саклана торган эштәге нөсхәсенә кушып куела.

5.54. Әгәр урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру өчен аның прокуратура органы белән килештерлүе таләп ителгән булса, җаваплы башкаручы тикшерү акты күчермәсен тикшерү уздыруны килештерү турында карарны кабул

иткән прокуратура органына җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерү актын төзегән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.55. Җаваплы башкаручы урынга чыгып уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу терки, анда Инспекциянең исеме, тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләр була, тикшерүне уздыручы вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яисә аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: урынга чыгып тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаган очракта җаваплы башкаручы тикшле язуны тикшерү актында терки.

Тикшерүләрне исәпкә алу журналы тегелгән, номерланган һәм күзәтчелек объектының мөһере (мөһер булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш.

5.56. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән күзәтчелек объекты, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта күзәтчелек объекты мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Инспекциягә тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.57. Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозулары ачыкланган очракта җаваплы башкаручы тикшерүне уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага хәбәрнамә җибәрә.

5.58. Тикшерүне тәмамлаганнан соң җаваплы башкаручы тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматның, зарури таләпләрнең бозылу очракларын, бирелгән күрсәтмәләр һәм административ хокук бозулар турында рәсмиләштерелгән беркетмәләр турында белешмәләрне теркәп, Инспекциянең рәсми сайтында билгеләнгән тәртиптә урнаштырылуын оештыра.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланган көннән соң өч эш көне эчендә.

5.59. «Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

– кушымталары белән бергә тикшерү акты;

– урынга чыгып уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) язу;

– тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештергән очракта – тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яисә) аның алынуына башкача дәлилләмә;

– административ процедура нәтиҗәләре турында тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән белешмәләр.

## «ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА АЧЫКЛАНГАН БОЗУ ФАКТЛАРЫНА КАРАТА ЧАРАЛАР КҮРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.60. Административ процедураны башлау өчен нигез булып зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары тора.

5.61. Тикшерү уздырганда ачыкланган бозу фактларына карата чаралар күрүгә җаваплы булган вазыйфаи затлар булып күзәтчелек объектына карата тикшерү уздырган, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләте бирелгән дәүләт торак инспекторлары (җаваплы башкаручылар) тора.

5.62. Тикшерү уздырганда зарури таләпләрнең бозылу очракларын ачыклаганда җаваплы башкаручы:

1) юридик затка, шәхси эшкуарга, бетерү чорларын һәм (яисә) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яисә муниципаль мөлкәткә зыян салынуны чикләү, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) бирә;

2) ачыкланган бозуларның бетерелүен, аларны кисәтүне, кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, милли китапханә фонды составына керүче, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, зыян салыну мөмкинлеген бетерүне, дәүләт иминлеген тәэмин итүне, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтүне контрольдә тоту буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

3) административ хокук бозу турында эш кузгата – административ хокук бозу турында беркетмә төзи;

4) административ хокук бозу турында эшне карый.

## АЧЫКЛАНГАН ЗАРУРИ ТАЛӘП БОЗЫЛУНЫ БЕТЕРҮ ТУРЫНДА КҮРСӘТМӘ БИРҮ

5.63. Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора, тикшерү акты белән бергә рәсмиләштерелә һәм юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры әлеге Регламентның 5.52 пункты нигезендә

тапшырыла (җибәрелә).

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең типик рәвеше шушы Регламентның 7 нче кушымтасында китерелде.

5.64. Үзенә карата тикшерү үткәрелгән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Инспекциягә тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы.

5.65. Бирелгән күрсәтмәләр Капиталь ремонт дәүләт программасын төзү һәм үтәлешен күзәтү һәм торак фонды объектларының торышын күзәтү дәүләт мәгълүмат системасында (ТФМ ДМС) теркәүгә алына.

5.66. Инспекциянең күрсәтмәне биргән вазыйфаи заты ачыкланган зарури таләпләрне бозылуларны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү чоры тәмамлангач планнан тыш тикшерү уздыруны оештыра. Күрсәтелгән нигез буенча тикшерүне әлеге Регламентта билгеләнгән тәртипкә туры китереп, күрсәтмәдә күрсәтелгән чордан соң алтмыш көннән соңга калмыйча уздырырга кирәк.

Күрсәтмәләрнең үтәлешен вакытында тикшерүне җаваплы башкаручының (дәүләт торак инспекторының) турыдан-туры җитәкчесе контрольдә тота.

5.67. Планнан тыш тикшерү уздырганда билгеләнгән чорда зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын юкка чыгару турында законлы күрсәтмәнең үтәлмәгәнлеге ачыкланса, җаваплы башкаручы:

1) РФ КоАП каралган административ хокук бозу турында эш буенча эш кузгата;

2) билгеләнгән чорда бетерелмәгән бозуларны юкка чыгару турында күрсәтелгән бозуларны бетерү вакытын күрсәтеп күрсәтмә бирә.

5.68. Әгәр тикшерү уздырганда юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге, алар тарафыннан биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, бүлмәләрне, җайланмаларны, шуңа охшаш объектларны, транспорт чараларын эксплуатацияләүнең, алар тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарларның (башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең) турыдан-туры гражданнарның гомеренә зыян китерү, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зыян салу, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычын тудыруы яисә мондый зыянның салынган булуы ачыкланса, Инспекция зыян салынуга юл куймау яки аның салынуын туктату буенча юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, шәхси эшкуарның эшчәнлеген РФ КоАП билгеләнгән тәртиптә вакытлыча тыю, гражданнарның гомере, сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч тудыручы продукцияне әйләнештән алу өлешенә кадәр

кичекмәстән чаралар күрергә һәм гражданнарга, шулай ук башка юридик затларга, шәхси эшкуарларга мөмкин булган теләсә нинди ысул белән зыян салыну куркынычы булуы һәм аны юкка чыгару ысуллары турында мәгълүмат җиткерергә бурычлы.

## АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУ ТУРЫНДА ЭШ КУЗГАТУ

5.70. Административ хокук бозу турында эш кузгатуга нигез булып түбәндәге очраклар тора:

1) административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан административ хокук бозу вакыйгасы булуга күрсәтә торган җитәрлек белешмәләрне турыдан-туры ачыклавы;

2) хокук саклау органнарыннан, шулай ук башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән административ хокук бозу вакыйгасы булуына күрсәтә торган мәгълүматлардан торучы материаллар килү;

3) физик һәм юридик затларның административ хокук бозу вакыйгасы булуына күрсәтә торган мәгълүматлардан торучы хәбәрләре һәм гаризалары, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларыннан хәбәрләр;

4) Инспекциянең законлы күрсәтмәсен билгеләнгән вакытында үтәмәү.

5.71. Административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән төзелә.

Әгәр дә, эшнең шартларын яисә үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган хокук бозучы турында белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителсә, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуны ачыклау вакытыннан башлап ике тәүлек дәвамында төзелә. Бу очракта вазыйфаи зат юридик затның, вазыйфаи һәм физик затның адресына почта аша хәбәрнамә белән, электрон документ рәвештә «Интернет» челтәреннән файдаланып яки мөмкин булган теләсә нинди ысул белән, әлеге Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән рәвештә административ хокук бозу турында беркетмә төзү өчен килү зарурлыгы турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) җибәрә.

5.72. Административ хокук бозу турында беркетмә җаваплы башкаручы тарафыннан әлеге Регламентның 9 нчы кушымтасында күрсәтелгән рәвештә төзелә.

5.73. Административ хокук бозу турында беркетмәгә имза салу процедурасыннан соң җаваплы башкаручы аның күчермәсен үзенә карата беркетмә төзелгән зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшыра.

5.74. Зат беркетмә күчермәсен алудан баш тарткан очракта, җаваплы башкаручы беркетмәдә тиешле язуны терки, аңа имза сала һәм беркетмә күчермәсен үзенә карата беркетмә төзелгән затның адресына, кулга тапшыру тамгасы белән почта аша җибәрә, бу хакта беркетмә кәгазендә күрсәтелә.

5.75. Беркетмә төзелгән вакыттан алып өч тәүлек эчендә:

Инспекция вәкаләтләренә карый торган административ хокук бозу эшләре җаваплы башкаручының турыдан-туры җитәкчесенә тапшырыла һәм алга таба административ тәҗрибә бүлегенә (җаваплы затка) юллана, ул аны өйрәнеп

чыкканнан соң Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) танышып чыгу һәм асылы буенча карап тикшерүне оештыру өчен тапшыра;

административ хокук бозу эшләре, аларны карап тикшерү вәкаләте судларга йөкләнгән очракта, дәүләт торак инспекторы тарафыннан турыдан-туры тиешле судка тапшырыла (җибәрелә).

5.76. Үтәү вакыты:

административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән төзелә;

эш шартларын яисә үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатыла торган физик зат турында белешмәләрне яки юридик зат турында белешмәләрне өстәмә ачыклау таләп ителгәндә, административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозуны ачыклау вакытыннан башлап ике тәүлек дәвамында төзелә;

административ тикшерү уздырылган очракта, административ хокук бозу турында беркетмә тикшерү тәмамланганнан соң РФ КоАП 28.7 статьясы күздә тоткан чорларда төзелә.

## АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУ ТУРЫНДА ЭШЛӘР КАРАУ

5.77. Карау өчен килгән административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозу турында эшне карый башлау өчен нигез булып тора.

5.78. Административ эшне карап тикшерүне Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) административ хокук бозу кылынган урын буенча эшне карап тикшерүгә тапшыру көненнән башлап, эш буенча карарның хокук бозу башкарылган вакыттан алып ике айлык чордан соңга калмыйча чыгарылган булырга тиешлеген исәпкә алып, 15 көнлек чорда гамәлгә ашыра.

5.79. Административ хокук бозу турында беркетмә төзелгәннән соң контрольлек буенча чара уздырган дәүләт торак инспекторы тарафыннан рәсмиләштерелгән, шулай ук дәүләт торак инспекторының турыдан-туры башлыгы тарафыннан тикшерелгән һәм имзаланган административ хокук бозу эше 3 календарь көне эчендә административ тәҗрибә бүлегенә тапшырыла.

5.80. Административ тәҗрибә бүлеге өч эш көне эчендә алынган материалларны карый, документларны рәсмиләштерүдә хаталар булмаган очракта, карау вакытын һәм урынын билгеләү турында билгеләмә төзи. Күрсәтелгән билгеләмәне административ тәҗрибә бүлеге, административ хокук бозу эшендәге материаллар белән бергә бер эш көне эчендә имза кую өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) тапшыра.

5.81. Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән рәвештәге административ хокук бозу эшен карау вакытын һәм урынын билгеләү һәм затларны чакырту турында билгеләмәгә имза сала һәм җибәрү өчен аны бер эш көне эчендә административ тәҗрибә бүлегенә тапшыра.

5.82. Хокукы булмаган затлар тарафыннан беркетмә төзелгән һәм эшнең башка материаллары рәсмиләштерелгән очракта, беркетмә дөрес төзелмәгән һәм

административ хокук бозу эше дөрес рәсмиләштерелмәгән очракта,

административ хокук бозу эше өч эш көне эчендә дәүләт торак инспекторына җитешсезлекләрне бетерү өчен шушы Регламентның 11 нче кушымтасында китерелгән рәвештә беркетмәне һәм эшнең бүтән материалларын кайтарып бирү турында билгеләмә юлы белән кайтарыла, әлеге билгеләмә дәлилләнгән булырга һәм ачыкланган, юкка чыгаруы таләп ителгән җитешсезлекләрне күрсәтергә тиеш.

5.83. РФ КоАП 24.5 статьясында каралган шартлар булганда, биш эш көне эчендә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар чыгарыла.

5.84. Билгеләмә яисә карар өч эш көне эчендә административ тәҗрибә бүлеге тарафыннан рәсмиләштерелә һәм Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалана. Кисәтүләре бетерелгәннән соң (өч эш көненнән артык түгел) документлар кабат административ тәҗрибә бүлегенә тапшырыла.

РФ КоАП 4.5 статьясында билгеләнгән административ җаваплылыкка тарту буенча дәгъва белдерүнең ике айлык чоры узып киткәнчегә кадәр эш каралган, ә аның буенча карар кабул ителгән булырга тиеш. Шушы вакыт узып китү белән гаепле зат административ җаваплылыкка тартылмый, ә эш буенча эш башкару карар чыгару юлы белән туктатылырга тиеш.

Административ хокук бозу турында эш үзенә карата административ хокук бозу эше буенча эш алып барыла торган зат, зыян күрүче һәм бүтән затлар катнашында карап тикшерелә.

5.85. Күрсәтелгән затлар юклыгында эш бары тик түбәндәге очракларда гына карала ала:

эшне карау урыны һәм вакыты турында аларга тиешенчә хәбәр итү турында язмача белешмәләр булганда, шулай ук алардан эшне карауны кичектереп тору турында үтенеч язуы килмәсә;

эш материалларында эшне алар катнашыннан башка карау турында гозер булса.

5.86. Шушы Регламентның 12 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә тиешле билгеләмә белән эшне карау кичектерелергә мөмкин.

5.87. Эшне карауны дәвам иттерү турында карар кабул ителгән очракта, эшне карауда катнашучы затларга аларның РФ КоАП 25.1-25.10 статьяларында каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатыла.

5.88. Эшне карау йомгаклары буенча Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан административ хокук бозу эше буенча карар чыгарыла, ул эшне карап бетерү тәмамлану белән әлеге Регламентның 13 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә кичекмәстән игълан ителә.

Административ хокук бозу эше буенча карар күчермәсе административ тәҗрибә бүлеге тарафыннан үзләренә карата шушы карар чыгарылган күзәтчелек объектының җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә яздыртып, шулай ук зыян күрүче затка аның гозере буенча тапшырыла яисә күрсәтелгән затларга күрсәтелгән карар чыгарылган көннән башлап өч көн эчендә кулга тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә.

5.89. Эшне караганнан соң дәүләт торак инспекторы ТФМ ДМС системасына административ хокук бозу эшен карау йомгаклары турында мәгълүмат кертә.

5.90. Зат бер яисә аннан күбрәк административ хокук бозуны кылганда, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан административ җәза

кылынган һәр административ хокук бозу очрагы өчен билгеләнә.

Зат тарафыннан административ хокук бозу составына керүче бер гамәл кылынганда (гамәл кылынмаганда), аның өчен РФ КоАП ике һәм аннан күбрәк статьяларында (статьялары өлешләрендә) җаваплылык каралганда, административ җәза күрсәтелгән гамәлне кылган (гамәлне кылмаган) затка билгеләнергә тиешле тагын да катырак административ җәза санкцияләре кысаларында билгеләнә.

5.91. Административ хокук бозуны кылу сәбәпләре һәм аны кылуга сәбәпче булган шартлар ачыкланган очракта, тиешле оешмалар һәм вазыйфалар адресына Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан күрсәтелгән сәбәпләрне һәм шартларны юкка чыгару буенча чаралар күрү турында йогынты акты чыгарылырга мөмкин, ул административ тәҗрибә бүлеге тарафыннан рәсмиләштерелә. Йогынты акты Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалана. Йогынты актының күчермәсе административ эшкә кушып куела.

5.92. Йогынты актында административ хокук бозуны кылу сәбәпләренә һәм моңа сәбәпче булган шартларны юкка чыгару буенча чаралар күрү турында таләп, хокук бозучының йогынты актын алган көннән бер ай эчендә карау бурычы һәм йогынты актын чыгарган вазыйфаи затка күрелгән чаралар турында хәбәр итү бурычы күрсәтелергә тиеш.

Йогынты актында күрсәтелгән таләпләрнең үтәлүен административ тәҗрибә бүлеге контрольдә тота.

5.93. Йогынты актын кабул итүдән һәм аңа имза салудан баш тарту аны чыгару өчен, шулай ук билгеләнгән чорларда аның таләпләрен үтәүгә каршылык була алмый.

5.94. Йогынты актын билгеләнгән вакытында үтәмәгән очракта акт белән беркетмә төзелә, алар административ җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

5.95. Административ хокук бозу эшен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан түбәндәгечә карар чыгарылырга мөмкин:

административ җәза билгеләү турында;

административ хокук бозу турындагы эш буенча эш башкаруны туктату турында;

5.96. «Тикшерүләрне уздырганда ачыкланган бозу фактларына карата чаралар күрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

1) ачыкланган бозуны юкка чыгару турында күрсәтмә, тикшерү актына кушымта булып тора;

2) административ хокук бозу турында беркетмә;

3) административ хокук бозу турында эш материаллары;

4) карар:

административ җәза билгеләү турында;

административ хокук бозу турындагы эш буенча эш башкаруны туктату турында;

5) административ процедура нәтиҗәләре турында тикшерүләрнең бердәм реестрына, ТФМ ДМС системасына кертелгән белешмәләр.

# «ЮРИДИК ЗАТЛАР, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАР БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТМИЧӘ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.97. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын оештыру һәм уздыру турында карар кабул итү яисә Инспекциягә гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгать яки гариза, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат килү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары торак фонды объектларын карау, тикшерү (алга таба – карау (тикшерү)) рәвешендә уздырыла.

5.98. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары Инспекциянең вазыйфаи затлары (дәүләт торак инспекторлары) тарафыннан үз компетенцияләре кысаларында мондый чараларны уздыруга Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан расланган биремнәр (алга таба – бирем) нигезендә уздырыла. Биремнең типик үрнәге Инспекция тарафыннан билгеләнә (әлеге Регламентның 14 нче кушымтасы).

5.99. Административ процедураны гамәлгә ашырганда түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) карау (тикшерү) турында карар әзерләү һәм кабул итү, бирем рәсмиләштерү;

2) карау (тикшерү);

3) карау (тикшерү) нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.100. Торак фонды объектларын карау (тикшерү) турында карар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тора.

Дәүләт торак инспекторы, торак фондын карау (тикшерү) турында йөкләмә алган көннән соң өч эш көненнән артмаган чорда, каралырга (тикшерелергә) тиешле торак фондына кагылышлы документларга анализ ясый һәм бирем проектын әзерли, аңа Бүлек башлыгыннан имза куйдырта һәм вазыйфаларның бүленеше нигезендә Инспекция башлыгы урынбасарына кул кую өчен юллый.

Инспекция башлыгы урынбасары бер эш көне эчендә бирем проектын карый, аңа кул куя һәм бирем проектын әзерләгән дәүләт торак инспекторына тапшыра.

Үтәү вакыты: дүрт эш көненнән артык түгел.

5.101. Биремдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) үзләренә карата юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары гамәлгә ашырыла торган юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемнәре;

б) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларының аталышлары;

в) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздыру өчен Инспекциянең җаваплы вазыйфаи затларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

г) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздыру вакыты;

д) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү чоры.

5.102. Торак фондын карау (тикшерү) визуаль күзәтеп чыгу рәвешендә уздырыла.

Тикшерүне уздырганда кирәкле чаралар исемлеге дәүләт торак инспекторы тарафыннан билгеләнә.

Виузаль карау (тикшерү) торак фонды элементларының техник торышын, аның инженерия системаларын техник үлчәү чараларыннан һәм җиһазларыннан файдаланмыйча бәяләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: биш эш көненнән артык түгел.

5.103. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары нәтиҗәләре буенча дәүләт торак инспекторы биремдә билгеләнгән чорда юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чарасын уздыру нәтиҗәләре турында хисап әзерли, ул Инспекция раслаган рәвештә төзелә, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан раслана.

5.104. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздырганда зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт торак инспекторы үз компетенциясе чикләрендә мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү зарурлыгы булганда, ачыкланган бозулар турында мәгълүматлар белән, Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) язмача рәвештә дәлилләнгән йогынты актын җибәрә.

5.105. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздырганда 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 5-7 өлешләрендә күрсәтелгән зарури таләпләрне бозарга әзерләнүләр яки бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланган очракта, Инспекция юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрә.

5.106. Карау нәтиҗәсендә ачыкланган зарури таләпләрне бозу очраклары турында мәгълүмат әлеге Регламентта каралган тәртиптә планнан тыш тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерүне алу өчен нигез булып хезмәт итә.

«Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын гамәлгә ашыру» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

1) юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын уздыруга бирем;

2) зарури таләпләрнең бозылу очраклары булу яисә булмау турында билгеләнгән фактлар;

3) ачыкланган бозулар турында мәгълүмат белән дәлилле йогынты акты;

4) зарури таләпләрне бозуны ярамаганлыгы турында кисәтү.

5) административ процедура нәтиҗәләре турында тикшерүләрнең бердәм реестрына, ТФМ ДМС системасына кертелгән белешмәләр.

## «СИСТЕМАЛЫ РӘВЕШТӘ КҮЗӘТҮ ҺӘМ АНАЛИЗЛАУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.107. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ уздыруга Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) әмернамәсе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

5.108. Зарури таләпләрнең үтәлешен системалы рәвештә күзәтүне һәм Инспекциягә килгән документларны, белешмәләрне һәм дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылган аларның эшчәнлеге турында мәгълүматларны анализлауны гамәлгә ашырганда түбәндәгеләр башкарыла:

1) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырылганда зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль закон нигезендә әлеге затларга аны тапшыру җаваплылыгы йөкләнгән мәгълүматларны анализлау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен күзәтү (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән).

5.109. Системалы рәвештә күзәткәндә һәм анализ ясаганда дәүләт торак инспекторы:

1) юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләрен әзерли;

2) документларны һәм материалларны туплый;

3) документларны һәм материалларны эшкәртә һәм анализлый;

4) системалы рәвештә күзәтү һәм анализ ясау нәтиҗәләре буенча документлар әзерли.

5.110. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау йомгаклары буенча дәүләт торак инспекторы хисап әзерли.

5.111. Системалы рәвештә күзәтүнең һәм анализлауның нәтиҗәләре Инспекция тарафыннан планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне планлаштырганда һәм уздырганда файдаланыла.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ ҮТӘЛҮЕН ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламентның һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләр билгеле торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләре саклануына һәм үтәлүенә, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүгә карата агымдагы контрольлек Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.2. Дәүләт функциясе үтәлешенең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әмернамәсе нигезендә оештырыла.

Контрольлек түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

дәүләт функциясе үтәлешенә планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру чорларын һәм ешлыгын тикшереп тору;

дәүләт функциясен башкарганда вазыйфаи затлар тарафыннан җибәрелгән

бозуларны ачыклау һәм юкка чыгару;

вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне карау һәм аларга җаваплар әзерләү.

Тикшерүләр уздыру ешлыгы:

планлы була – еллык эш планнары нигезендә;

планнан тыш була – (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча).

Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча мәнфәгатьле затларның хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

6.3. Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручы Инспекциянең вазыйфаи затлары дәүләт функциясен үтәү кысаларында административ процедураларны тормышка ашыру чорларын һәм тәртибен саклау буенча шәхсән җаваплы була.

6.4. Дәүләт функциясенең үтәлүен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан тикшереп тору «Интернет» челтәрендә Инспекциянең рәсми сайтында, торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында (ТКХ ДМС) урнаштырыла торган тиешле мәгълүматлардан файдаланып, шулай ук Инспекциягә мөрәҗәгать итү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

6.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары, дәүләт функциясе үтәлгәндә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган очракта, дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына тикшерү уздыру турында гозер белән Инспекциягә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

6.6. Төбәк дәүләт торак күзәтчелеге үтәлешендә иҗтимагый контрольлек иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциясез бүтән оешмалар тарафыннан аларның уставлары нигезендә, шулай ук гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына тапшырылган иҗтимагый контрольлек нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә зарури каралырга тиеш.

## 7. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮЧЕ БАШКАРМА ОРГАННЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Мәнфәгатьле затлар дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерергә хокуклы.

7.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Инспекциянең, аның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышындагы гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм алар тарафыннан кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарлар тора.

7.3. Мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән яисә почта аша җибәрелгән рәвештә, Инспекциянең tatgi@tatar.ru электрон адресы, яисә Инспекциянең www.gji.tatar.ru рәсми сайтындагы Интернет-кабул итү системасы аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә Инспекциягә мөрәҗәгать

(шикаять) килү судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез була.

Инспекция башлыгына телдән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгатькә (шикаятькә) җавап, мөрәҗәгать иткән затның ризалыгы белән, шәхси кабул итү барышында бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасында язу теркәлә. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача рәвештә җавап бирелә.

7.4. Инспекциягә яисә, компетенцияләре нигезендә, югары торучы вазыйфаи затка килгән шикаять зарури каралырга тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карап тикшерүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Шикаятькә җавап яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап түбәндәге очракларда бирелми:

1) язмача рәвештәге мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән затның фамилиясе, исеме яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (мөрәҗәгать (шикаять) юридик зат тарафыннан тапшырылса, юридик затның аталышы һәм урнашкан урыны буенча адресы) күрсәтелмәсә (әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнеп ятуы, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать (шикаять) Инспекциягә җибәрелергә тиеш);

2) мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) суд карарына шикаять белдерелгәндә (күрсәтелгән мөрәҗәгать теркәүгә алынган көннән соң 7 (җиде) көн эчендә мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән затка әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып җибәрелә);

3) мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булганда (күрсәтелгән мөрәҗәгатьне (шикаятьне) Инспекция анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән гражданинга хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы);

4) язмача мөрәҗәгатьнең тексты укылышлы булмаса (Инспекция мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң 7 (җиде) көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәргән затка бу хакта хәбәр итә, әгәр дә фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса);

5) язмача мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән затка элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә (шикаятьләргә) бәйле рәвештә асылы буенча язмача берничә мәртәбә җавап бирелгән булса һәм бу вакытта мөрәҗәгатьтә (шикаятьтә) яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә. Инспекция башлыгы (башлык урынбасары), Инспекциянең вазыйфаи заты, яисә Инспекциянең моңа вәкаләте булган заты, күрсәтелгән мөрәҗәгать (шикаять) һәм элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) шул бер үк дәүләт органына яки шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булу шарты белән, чираттагы мөрәҗәгатьнең (шикаятьнең) нигезсез булуы турында карар кабул итәргә һәм мәнфәгатьле зат белән әлеге мәсьәлә буенча язышуны туктатырга хокуклы. Бу карар турында мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән затка хәбәр ителә;

6) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса (мөрәҗәгатьне (шикаятьне) җибәргән мәнфәгатьле затка күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә).

Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирелергә мөмкин булган сәбәпләр алга таба юкка чыгарылган очракта, гражданин мөрәҗәгатьне (шикаятьне) тиешле дәүләт органына (тиешле вазыйфаи затка) яңадан җибәрергә хокуклы була.

7.5. Мәнфәгатьле затлар мөрәҗәгатьне (шикаятьне) нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы.

Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар Инспекция адресына язмача рәвештә тиешле гарызнамәне язмача яисә электрон рәвештә җибәрергә тиеш. Инспекциянең вазыйфаи затлары соратыла торган белешмәләрне һәм документларны гарызнамә теркәлгән көннән соң 30 календарь көненнән артмаган чорда бирергә бурычлы.

7.6. Мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате (шикаяте) тиешле җитәкчегә буйсынганлык буенча тапшырыла.

Инспекциянең территориаль органының вәкаләтле вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына мөрәҗәгать (шикаять) Инспекциянең территориаль органы башлыгы тарафыннан карала.

Инспекциянең территориаль органы башлыгының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына мөрәҗәгать (шикаять) Инспекция башлыгы урынбасары һәм Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан карала.

Инспекция башлыгы урынбасарының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына мөрәҗәгать (шикаять) Инспекция башлыгы тарафыннан карала.

Инспекция, Инспекция башлыгы гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына мөрәҗәгать (шикаять) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.7. Мөрәҗәгатьне (шикаятьне) карап тикшерү чоры аны Инспекциядә теркәүгә алган вакыттан башлап 30 календарь көненнән артып китәргә тиеш түгел.

7.8. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт функциясен үтәү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән шикаятьне канәгатьләндерү;

төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру.

7.9. Шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мәнфәгатьле затка язмача рәвештә дәлилле җавап җибәрелә. Электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатькә (шикаятькә) җавап мәнфәгатьле затка электрон документ рәвешендә шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яки язмача рәвештә шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә. Мөрәҗәгатьне (шикаятьне) канәгатьләндермичә калдырган очракта, җавапта мондый карарга дәлилле нигезләү булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымта

| Территориаль орган | Адресы | Хезмәт күрсәтә торган территорияләре | Телефон |
|---|---|---|---|
| Әлмәт зонасы торак инспекциясе | Әлмәт ш., Ленин ур., 47 й. | Әлмәт, Мөслим, Сарман һәм Чирмешән муниципаль районнары | 8(8553) 45-77-75 |
| Бөгелмә зонасы торак инспекциясе | Бөгелмә ш., Гафиатуллин ур., 18 й. | Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Лениногорск һәм Ютазы районнары | 8(85594) 4-43-96 |
| Алабуга зонасы торак инспекциясе | Алабуга ш., Пролетар ур., 46 й. | Алабуга, Әгерҗе, Мамадыш һәм Менделеевск районнары | 8(85557) 3-10-77 |
| Яр Чаллы зонасы торак инспекциясе | Яр Чаллы ш., ГЭС, 8/7 «Б» й., ком. 708 | Яр Чаллы ш., Тукай, Минзәлә һәм Актаныш районнары | 8(8552) 71-38-42 |
| Түбән Кама зонасы торак инспекциясе | Түбән Кама ш., Төзүчеләр пр. ур., 6а, а/я 44 | Түбән Кама, Зәй һәм Яңа Чишмә районнары | 8(8555) 42-37-33 |
| Чистай зонасы торак инспекциясе | Чистай ш., Ленин ур., 1 | Чистай, Алексеевск, Әлки, Аксубай, Нурлат һәм Спас районнары | 8(84342) 5-05-13 |
| Үзәк инспекторлык бүлеге | Казан ш., З.Кызыл ур., 15/9 й. | Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Тәтеш һәм Теләче районнары | 8(843) 236-96-53 |
| Казан шәһәре торак инспекциясе | Казан ш., Декабристлар ур., 179 й. | Казан шәһәре | 8(843) 555-69-01 |

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең
БЛОК-СХЕМАСЫ



Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## Төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – баш дәүләт торак инспекторы (1 бер.);
2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарлары – баш дәүләт торак инспекторы урынбасарлары (4 бер.);
3. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарлары – зона торак инспекцияләре башлыклары (6 бер.);
4. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы (1 бер.).
5. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы (1 бер.);
6. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы урынбасары (1 бер.);
7. Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы урынбасары (1 бер.);
8. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (3 бер.);
9. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы консультанты (3 бер.);
10. Торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлеге башлыгы (1 бер.);
11. Торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (1 бер.);
12. Торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлегенең әйдәп баручы консультанты (1 бер.);
13. Торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлеге әйдәп баручы белгече – эксперт (2 бер.);
14. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлеге башлыгы (1 бер.);
15. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (2 бер.);
16. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты (1 бер.);
17. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече (1 бер.);
18. Казан шәһәре торак инспекциясе консультанты (6 бер.);
19. Зона торак инспекциясе консультанты (17 бер.);
20. Казан шәһәре торак инспекциясенең әйдәп баручы белгече – эксперт (18 бер.);
21. Зона торак инспекциясенең әйдәп баручы белгече – эксперт (20 бер.);
22. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече (1 бер.);
23. Казан шәһәре торак инспекциясенең 1 разрядлы белгече (1 бер.);
24. Зона торак инспекциясенең 1 разрядлы белгече (6 бер.).

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 4 нче кушымта

## Ведомствоара хезмәттәшлек буенча соратыла торган документлар һәм белешмәләр исемлеге

| Гарызнамә җибәрелә торган орган | Сорала торган документлар яки белешмәләр |
|---|---|
| Федераль салым хезмәте | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр |
| Федераль салым хезмәте | Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр |
| Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәт идарәсе | Биналар буенча мәгълүмат: милекчесе, мәйданы һ.б. |

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**Ул. Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ**
**З.Кызыл ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111**

**тел/факс. 236-91-44. E-mail:** tatgi@tatar.ru, **сайт: www.gji.tatarstan.ru**

**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт торак инспекциясе**
**ӘМЕРНАМӘСЕ**

_______________________________________________ тикшерү уздыру турында
юридик затка, шәхси эшкуарга (планлы/планнан тыш, документар/урынга чыгып)

«____« ____________ ______ел. №______

1. Түбәндәгегә карата тикшерү уздырырга ____________________________________________

_______________________________________________________________________________

(юридик затның аталышы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

2. Урнашкан урыны: ____________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(юридик затның (филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең), шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыннары һәм (яисә) алар тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектлары урыны)

3. Түбәндәге(ләр)не тикшерү уздыруга вәкаләтле зат(лар) итеп билгеләргә: ______________

_______________________________________________________________________________

(тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы)

4. Түбәндәге затларны экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре сыйфатында тикшерүне уздыруга җәлеп итәргә: ________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(тикшерүне уздыруга җәлеп итеәлә торган экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) һәм (яисә) эксперт оешмасының аталышы, аккредитация турында таныклык реквизитларын һәм аккредитация турында таныклык биргән аккредитацияләү органы аталышын күрсәтеп)

5. Бу тикшерү түбәндәгеләр кысасында уздырыла ________________________________

_______________________________________________________________________________

(дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төренең (төрләренең) аталышы,
«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында функциянең (функцияләрнең) реест номеры (номерлары))

6. Билгеләргә:
әлеге тикшерүне уздыруның максаты: ____________________

____________________

____________________

Уздырыла торган тикшерүнең максатларын билгеләгәндә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) планлы тикшерү уздырылган очракта:

– планлы тикшерүләр уздыруның расланган еллык планына сылтама;

– тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлегенең) реквизитлары, әгәр планлы тикшерүне уздырганда тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга тиешле булса;

б) планнан тыш тикшерү уздырылганда:

– тикшерелә торган затка элегрәк бирелгән, үтәү өчен вакыты узган ачыкланган бозуны бетерү турында күрсәтмә реквизитлары;

